ПӘНҖЕШӘМБЕ
1 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 26 (5826)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АЛДЫНГЫЛАРЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА КИҢӘШМӘСЕ МӨРАҖӘГАТЕ

Орденлы Татарстанның социалистик авыл хуҗалыгының барлык колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына, совхоз һәм МТС эшчеләренә һәм эшче хатын-кызларына, белгечләренә, фенни һәм җитәкче работникларына

Кадерле иптәшләр!

Социалистик игенчелек елдан-ел яңадан-яңа уңышлар яулап ала. Коллектив хезмәт, куәтле машина техникасы, алдынгы агрономия һәм зоотехника фәнен кертү—илебездәге колхозларга һәм совхозларга элек һич тә күрелмәгән иген уңышын һәм терлекчелекнең чәчәк атуын тәэмин итәләр. 1939 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе бу гаят зур җиңүләрне ачык һәм ышандырырлык итеп күрсәтте.

Колхозларны, совхозларны һәм МТС ларны ныгыту турында, хезмәт ияләренең тормышын яхшырту турында Сталинчыл мәхәббәт һәм кайгыртучанлык белән җылытылган социалистик игенчелек алдынгылары хезмәт батырлыгы могҗизалары күрсәтәләр. Алтай крае колхозчыларының данлыклы ефремовчылык хәрәкәтен башлап җибәрүче Ефремовның, Чумаковның һәм башкаларның исемнәре безнең илдә генә түгел, бәлки чит илләрдә дә маглүм. Хезмәтне звенолап оештыру һәм агротехниканы комплекслап куллану нәтиҗәсендә ефремовчылар үзләренең участкыларында бөртекле ашлыклар, бәрәңге һәм техник культуралар буенча дөньяда иң югары уңыш алалар.

Безнең орденлы Татарстан республикасының зур уңышлары күргәзмәдә күрсәтелде. Күргәзмәдә ТАССР дан 457 колхоз һәм колхоз, совхоз алдынгыларыннан 2.600 кеше катнашты.

Соңгы ике елда һава шартлары начар булды. Шуңа карамастан, Советлар Союзы 1939 нчы елны (1938 нче елдагы кебек үк) патша Россиясендә иң уңышлы елларда җыеп алганга караганда күбрәк уңыш алды.

Һава шартлары нинди генә булганда да республикабыздагы югары иген уңышы алучы алдынгы колхозларның казанышлары гаять зур һәм чиксез мөмкинлекләр барлыкны күрсәтәләр.

Октябрь районының „Төбәк“ колхозы соңгы өч елда (1937—1938—1939 нчы елларда) гектарыннан уртача 84 пот, „Приютовка“ колхозы—94 пот, „Труженик“ колхозы 108 пот уңыш алдылар.

Биектау районының Буденный исемендәге колхозы 1939 нчы елны яровойлаштырылган бодай буенча гектарыннан 97 пот уңыш алды. Әтнә районының Ленин исемендәге колхозы гектарыннан 106,5 пот, Юдино районының „Яңа Тормыш“ колхозы—51 гектар җирнең һәр гектарыннан 134 пот, ә 12 гектар җирнең һәр гектарыннан—146 пот арыш уңышы алды. Әтнә районының Киров исемендәге колхозы үткән корылыклы елда 630 гектар җирнең һәр гектарыннан 76 пот арыш уңышы алды. Норлат районы „Кызыл Урманчы“ колхозының иптәш Сафин бригадасы һәр гектардан 17,5 центнер арпа алды. Мамадыш районының „Хәсәнша“ колхозы 1939 нчы елны һәр гектардан 78 пот, Тельман районының Ленин исемендәге колхозы—90 пот, Тәкәнеш районының „Новая Жизнь“ колхозы — 93 пот бөртекле ашлык уңышы алды.

Чистай районы, „Дружба“ колхозының иптәш Ионычев бригадасы 1939 нчы елны һәр гектардан 96 пот бодай, 120 пот тары уңышы алды. Әлмәт районы, „Морат“ колхозының иптәш Ибраһимов бригадасы 113 пот тары уңышы алды.

Данлыклы Совет патриотларының бу хезмәт героизмыннан, югары уңыш өчен, колхозларның чәчәк атулары өчен армый-талмый көрәшүләреннән шактый күп үрнәкләр күсәтергә мөмкин. Алар Татарстанның һәрбер районында—урманлы һәм далалы зонасында бар.

Моңардан нинди нәтиҗә ясарга кирәк соң?

Нәтиҗә үзеннән-үзе ясала: бөтенесе колхозчыларның, совхоз һәм МТС эшчеләренең үзләренең бердәм булып намус белән эшләүләренә, алдынгы агротехниканың игенчелеккә никадәр дөрес һәм эзлекле төстә кертелүенә бәйләнгән. Нак әнә шул әһәмиятле шартларны саклау (намуслы хезмәт һәм агротехниканы дөрес куллану) республикабызның алдынгы колхозларына, һава шартлары нинди булуга карамастан, ныклы һәм югары иген уңышы алу мөмкинлеге бирәләр. Алдынгылардан үрнәк алып, һәрбер колхоз мондый нәтиҗәләргә ирешә ала.

Кадерле иптәшләр!

Туган атабыз, сөекле остазыбыз һәм юлбашчыбыз иптәш Сталин ВКП(б) ның XVIII нче съезды трибунасыннан социалистик игенчелек алдына сугышчан бурыч—ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерү бурычын куйды.

Моңа җавап итеп илебездә авыл хуҗалыгы алдынгыларының, Сталин заданиесен срогыннан алда үтәргә һәм арттырып үтәргә омтылучыларның куәтле хәрәкәте күтәрелде. Сталинград өлкәсендә 1939 нчы елны һәр гектардан йөз пот уңыш алган йөзпотчы бригадирлар хәрәкәте башланды. Сталинград өлкәсенең йөзпотчы бригадирлары үзләренең киңәшмәләрендә һәр гектардан йөз пот уңыш алу өчен Бөтенсоюз ярышы җәелдерергә чакырып Советлар Союзының барлык колхозчыларына, кырчылык һәм трактор бригадалары бригадирларына һәм агрономнарга мөраҗәгать иттеләр.

Без, Татарстан авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсендә катнашучылар, Сталинград өлкәсенең йөзпотчы бригадирларының чакыруын кабул итәбез, һәр гектардан йөз пот уңыш алу өчен, ел саен 8 миллиард пот ашлык җыеп алу турында иптәш Сталин заданиесен үтәү өчен Бөтенсоюз социалистик ярышына кушылабыз һәм Татарстанның барлык колхозчыларын, колхозчы хатын-кызларын, совхоз һәм МТС эшчеләрен, эшче хатын-кызларын, агрономнарны һәм авыл хуҗалыгының фән работникларын шуңа чакырабыз.

1940 нчы елны югары, ныклы, Сталинчыл уңыш алу турындагы йөкләмәбезне колхоз һәм совхоз производствосында үзебезне аямыйча тырышып эшләү белән ныгытыйк.

Барыннан да элек, язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп хәзерләник.

Орлыкларны җентекләп хәзерләүнең хәл иткеч әһәмияте бар. Ләкин безнең республикада бу әһәмиятле чара канәгатьләнерлек үткәрелми. Орлыкларны туплау, чистарту һәм аларның сыйфатын тикшерү акрын бара. Бу әһәмиятле тармакта артта калуга моннан соң түзеп торып булмый. Орлыклык һәм страховой фондлар туплауны, колхозлар арасында гади орлыкларны сортлыларга алмаштыруны шушы елның 20 нче февраленә кадәр тәмам итәргә, барлык орлыкларны чисталыгы һәм тишелүчәнлеге буенча чәчү кондицияләренә кадәр җиткерергә, орлыкларны бозылудан һәм урланудан тулысынча саклауны тәэмин итәргә кирәк. Исегездә тотыгыз, иптәшләр, чәчүлек орлык, ул—1940 нчы ел уңышының алтын фонды. Орлыкларны яхшы хәзерләгез һәм яхшы саклагыз.

Язгы чәчүнең уңышы трактор паркын хәзерләүгә бәйле булачак. Безгә быел яз көне 843.000 гектар җир сөрергә туры киләчәкне онытмаска кирәк.

Трактор паркына ремонт ясауны срогыннан алда тулысынча тәгалләгән Нөркәй, Тымытык һәм Теләче МТС лары коллективларын киңәшмә чын күңелдән котлый һәм Татарстан МТС ларының һәм совхозларының барлык работникларын алдынгы МТС ларның тәҗрибәләрен үзләренә күчерергә, социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте нигезендә тракторларга һәм тагылма инвентарьларга ремонт ясауны билгеләнгән срокларда тәгалләргә чакыра.

Киңәшмә ремонтта артта калучы Зөя, Димитров, Кукмара, Әлки, Тат. Ходяш һәм Чурибураш МТС лары җитәкчеләреннән һәм коллективларыннан эштә хурлыклы темпларны кискен рәвештә бетерүне һәм моннан соң һич тә түзеп тормаслык хәлне төзәтүне таләп итә.

Киңәшмә барлык колхоз председательләрен һәм бригадирларны язгы кыр эшләренә сөрү һәм чәчү инвентарен, транспортны һәм сбруйларны җентекләп хәзерләүне тәэмин итәргә чакыра.

Колхоз аты язгы кыр эшләрендә зур урын тотачак. Атны иң игтибарлы төстә тәрбияләүне, аңа саклык белән карауны тәэмин итәргә кирәк. Чәчү башланганга кадәр аз көчле атларны тулы көчкә кайтару өчен аларны хәзердән үк ялга куярга, ә кыр эшләре башланудан 15—20 көн алда барлык эш атларын ялга һәм көчле рәвештә ашатуга куярга кирәк. Һәрбер колхозда һәм совхозда эш атлары өчен чәчү алдыннан булачак чорына һәм язгы эшләр вакытына кирәкле санда тупас һәм концентрат азыкларны хәзердән үк кирәкле күләмдә хәзерләп куярга кирәк. Бу фондлар нык сакланырга тиешләр.

Киңәшмә барлык районнарның һәм колхозларның җитәкчеләрен, җир органнарының барлык работникларын хезмәтне оештыру мәсьәләләренә аеруча игтибар бирергә чакыра. Әйдәгез, иптәшләр, быел колхозларның барсында да хезмәтне оештыруның звенолар системасын тормышка ашырыйк. Бу система илебездәге алдынгы колхозларның тәҗрибәсендә үзен тулысынча аклады. Ул бердәм һәм төгәл эшләүне, хезмәт дисциплинасын күтәрүне тәэмин итә. Сталинчыл югары иген уңышы өчен көрәштә колхозчыларның иҗад талантлары чәчәк атуга ярдәм итә.

Кадерле вакытны әрәм итмичә, даими звенолар төзүгә хәзердән үк керешергә, һәрбер звеного чәчү участкысы беркетергә, һәрбер звено буенча агротехника чаралары планы төзергә һәм аларны үтәүгә керешергә кирәк. Звено җитәкчеләре итеп иң яхшы стахановчы колхозчыларны, югары уңыш мастерларын билгеләргә кирәк. Язгы чәчүгә хәзерләнүне хезмәтне звенолап оештыру системасы нигезендә үткәрергә кирәк.

Техниканы үзләштергән кадрлар барсын да хәл итәләр. Иптәш Сталин безне әнә шулай өйрәтә. Колхозларыбыз, совхозларыбыз һәм МТС ларыбыз өчен квалификацияле йөзләрчә һәм меңнәрчә работниклар хәзерләргә һәм кадрлар хәзерләү буенча билгеләнгән планнарны тулысынча үтәргә кирәк. Хатын-кызлардан тракторчылар, комбайнчылар, бригадирлар һәм звено башлыклары хәзерләүгә аеруча игтибар бирергә кирәк.

Хатын-кызларны квалификацияле эшкә, социалистик авыл хуҗалыгының җитәкче постларына кыюырак һәм кискенрәк төстә күтәрергә кирәк.

Шуның белән бергә, барлык колхозчыларны, МТС һәм совхоз эшчеләрен агротехника белеме белән коралландырырга кирәк. Бурыч—һәрбер колхозда, совхозда һәм МТС та агрономия укулары оештырудан, агрономия түгәрәкләренең һәм стахановчылар мәктәпләренең киң челтәрен төзүдән гыйбарәт. Язгы чәчүгә кадәр кышкы агрономия чараларын һәм чәчү агротехникасын өйрәнергә кирәк. Барыннан да элек, алдынгы колхозларга, бригадаларга һәм звеноларга югары уңыш алуны тәэмин иткән агротехника чараларын җентекләп һәм һәр яклап өйрәнергә кирәк. Әйдәгез, иптәшләр, ефремовчылар звеноларының эш тәҗрибәләрен, Сталинград өлкәсе йөзпотчыларының тәҗрибәләрен, Татарстандагы алдынгы колхозларның һәм бригадаларның эш тәҗрибәләрен җентекләп өйрәник һәм аларны үзебезнең практик эшебездә кулланыйк.

Алдынгы агротехниканы кертүгә бер минутка да соңга калмыйча большевикларча керешергә кирәк.

Кар тоту—кышкы агрономия чараларының иң әһәмиятлесе. Ефремовчылар, йөзпотчылар туфракта дым калдыру өчен ныклап көрәшәләр һәм, шулай итеп, югары иген уңышы алуның әһәмиятле шартларының берсен тудыралар. Без барлык колхозчыларны һәм колхозчы хатын-кызларны, колхоз председательләрен, бригадирларны һәм звено җитәкчеләрен кар тоту планын үтәп кенә калмаска, бәлки арттырып үтәргә һәм кар тота торган бөтен мәйданда кар калынлыгының кимендә 50—60 сантиметр булуын тәэмин итәргә чакырабыз. Карны беренче чиратта уҗым культуралары һәм күп еллык үлән чәчүлекләрендә тотарга кирәк.

Бу әһәмиятле эшкә вакытны кызганмагыз, иптәшләр, карны мөмкин кадәр артыграк тоту, кар катлавын мөмкин кадәр калынрак итү—өстәмә рәвештә иген уңышы алу, хезмәт көненә өстәмә килограмм ашлык алу дигән сүз икәнлекне исегездә тотыгыз.

Яз көне, кар эрегән вакытта җирне тырмалау һәм башка юллар белән кырда кар суларын тотып калу өчен барлык чараларны күрергә кирәк.

Без шулай ук иген уңышын күтәрүдә җирле ашламалар, беренче чиратта тирес кебек әһәмиятле чаралардан да тулысынча файдаланырга чакырабыз. Һәрбер колхозда һәм совхозда бөтен тирес запасын дөрес саклауны һәм аңардан дөрес файдалануны оештырырга кирәк. Тирес чыгару планы үтәлергә һәм арттырып үтәлергә тиеш. Болардан тыш һәрбер звено, бригада, колхоз, совхоз көл һәм кош тизәге җыюны һәм аларны саклауны оештырырга һәм иген уңышын күтәрүдә алардан тулысынча файдаланырга тиеш. Дәүләт тарафыннан җибәрелә торган барлык минераль ашламаларны кышкы юл белән Сельхозснаб складларыннан вактында ташып куярга һәм аларны ябулы биналарда язга кадәр сакларга кирәк.

Кышкы чордагы бөтен эшне язгы чәчүгә тулы хәзерлек белән каршы алырлык итеп оештырырга кирәк.

Без „Колхозларда бөртекле ашлык культуралары чәчүлекләрен планлаштыру тәртибе турында“ һәм „Бөртекле ашлык культураларының сортлы чәчүлекләрен планлаштыру турында“ СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарларын киң рәвештә өйрәнергә һәм тормышка дөрес үткәрергә чакырып барлык колхозчыларга һәм колхозчы хатын-кызларга, барлык районнарның, МТС ларның, колхозларның, бригадаларның, звеноларның җитәкчеләренә мөраҗәгать итәбез. Бу документлар—югары иген уңышы өчен көрәштә куәтле күтәргеч. Партиянең һәм хөкүмәтнең шушы карарлары нигезендә һәрбер колхозда чәчү планнары төзергә кирәк. Бу планнар шулай итеп төзелергә тиешләр ки, һәрбер культураны урнаштырганда колхозчыларның гаять бай тәҗрибәсе, алдынгы агротехника таләпләре, туфрак шартлары искә алынырга, иң яхшы әлгәрләр сайлап алынырга тиеш. Гомуми колхоз планы төзелгәннән соң һәрбер бригадада һәм звенода чәчү эшләре буенча конкрет планнар төзелергә тиеш.

Яз җитү белән бөтен туңга сөрелгән җирне вактында 2—3 көндә тырмаларга, туңга сөрелгән җирләрне яз көне культивацияләү планын үтәргә һәм арттырып үтәргә кирәк. Иртә чәчелә торган бөртекле культуралар чәчүне 5—7 көндә үткәрергә, чәчүлекләрне көндәлек тәрбияләүне оештырырга кирәк.

Кар эрү белән уҗымнарны тукландырырга хәзердән үк хәзерләнергә һәм аларны соңыннан тырмаларга кирәк. Орлыкларны яровойлаштыру планын тулысынча үтәргә кирәк. Техник культуралар чәчүлекләренә һәм аларны тәрбияләүгә өзлексез игтибар бирелергә тиеш.

Колхоз бригадаларының трактор бригадалары белән бердәм эшләүләре язгы чәчүнең уңышы өчен, югары иген уңышы өчен көрәштә аеруча әһәмият тотачак. МТС һәм колхоз җитәкчеләренең, колхоз һәм трактор бригадалары бригадирларының игтибарын без эшнең нак әнә шул ягына юнәлдерәбез. Исегездә тотыгыз, иптәшләр, Сталинград өлкәсендә йөзпотчылар хәрәкәте гүзәл уңышларга нак менә колхоз һәм трактор бригадалары эшендә ныклы элемтә булу нигезендә ирешә. Бу хәрәкәтне башлап җибәрүчеләр Хопер районының „12—я годовщина Октября“ колхозы бригадиры Аркадий Гуров һәм Хопер МТС ының трактор бригадасы бригадиры Георгий Козленков булдылар. Алар бригададагы чәчүлекләрнең һәрбер гектарыннан кимендә йөз пот бөртекле ашлык алу турында бергәләп йөкләмә алдылар. Алар үзләренең сүзләрендә тордылар. А. Гуров үз бригадасындагы 428 гектар чәчүлектән 120 шәр пот уңыш алды.

Һәрбер трактор бригадасының эш планын хәзердән үк уйлап куярга, бу бригаданың колхоздагы кайсы кырчылык бригадасы участкысын эшләячәген төгәл билгеләргә кирәк. Трактор бригадасын колхоз бригадасының һәм аерым звеноларның эш планнары белән алдан ук таныштырып куярга кирәк. Югары уңыш өчен көрәштә тракторчылар бригадасының колхоз бригадасы белән бергәләп төзелгән конкрет планы булырга тиеш. Шушы план нигезендә колхоз бригадасы белән тракторчылар бригадасы арасында югары уңыш өчен көндәлек социалистик ярыш җәелдерелергә тиеш.

Иптәшләр, колхоз һәм трактор бригадаларының бригадирлары!

Бер-берегез белән кулга-кул тотынып эшләгез, югары уңыш өчен көрәштә бергәләп уңышка ирешегез. Татарстанның һәрбер районында һәм МТС ында йөз пот иген уңышы мастерлары—үзләренең Гуровлары һәм Козленковлары булсын.

Югары уңыш өчен көрәшне социалистик терлекчелекне үстерү турында кайгыртучанлык белән нык рәвештә бергә бәйләп алып барырга кирәк. Колхозларда терлекчелекне үстерү турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын нык һәм тайпылышсыз тормышка үткәрергә кирәк.

Татарстанның колхозларында һәм совхозларында чын энтузиаст—терлекчеләр аз түгел. Теләче районының иптәш Булатов җитәкчелегендәге „Марс №2“ колхозы җәмагать терлекчелеген үстерү турында кайгыртучанлык үрнәге күрсәтә. Бу колхозда терлекләр авырлыклары һәм продуктлылыклары буенча группаларга бүленгәннәр, барлык терлек азыгы исәпкә алынган һәм акт буенча ферма мөдиренә тапшырылган, тукландыру планы төзелгән, азыкларны алдан эшкәртү оештырылган, терлекләр норма буенча туйдырылалар.

Минзәлә районының Ленин исемендәге колхозының колхозчы иптәш Урашникова җитәкчелегендәге товарлыклы сөтчелек фермасы һәрбер фураж сыерыннан елына уртача 2.207 литр сөт алуга ирешә. Октябрь, Минзәлә, Калинин һәм башка районнарның күп кенә колхозлары да колхоз терлекчелеген үстерүдә зур уңышларга ирешәләр.

Бурыч—социалистик терлекчелек эшен тагын да алга таба алып барудан, терлекләр санын арттыру буенча дәүләт планын үтәүне тәэмин итүдән, һәрбер колхозда кимендә икешәр ферма—мөгезле эре терлекләр фермасы һәм дуңгыз яки сарык үрчетү фермасы булдырудан гыйбарәт.

Быел терлекләрне кышлатуның кыенлыкларын искә алып, без терлекләрне иң җентекле төстә тәрбияләүне, барлык терлекләрне һәм бигрәк тә яшь терлекләрне тулысынча саклап калуның кирәклегенә колхоз һәм ферма җитәкчеләренең игтибарын аеруча юнәлдерәбез. Булган азыкны гаять зур игтибар белән сакларга һәм үлчәп кенә тотарга, азыкны әрәм-шәрәм итүнең аз гына күренешләрен дә бетерә барырга кирәк, иптәшләр.

Чәчү планнарын 100 проценты белән үтәү турында, техник культуралар, яшелчәләр, бәрәңге, үләннәр, силос культуралары һәм азык тамырлар буенча югары уңыш алу турында кайгыртырга кирәк. Бу культураларны барлык чәчү мәйданына җитәрлек итеп тулысынча һәм үз вактында хәзерләргә.

Югары уңыш өчен, социалистик терлекчелекнең чәчәк атуы өчен ныклы көрәштә фән учреждениеләренә һәм авыл хуҗалыгы белгечләренә—агрономнарга, зоотехникларга, фән работникларына алдынгы урын туры килә. Барлык колхозларда массовый төстә агрономия укулары оештыру эше алар җилкәсенә төшәргә тиеш. Алар агротехниканы һәм зоотехниканы колхоз һәм совхоз производствосына кертүнең җитәкчеләре булырга тиешләр. Алар югары уңыш мастерларының үсүенә көндәлек ярдәм күрсәтергә тиешләр.

Иптәшләр, район җир бүлекләренең һәм МТС ларның агрономнары һәм зоотехниклары, университетның, авыл хуҗалыгы һәм ветеринария институтларының, тәҗрибә станцияләренең галимнәре һәм фәнни-тикшеренү работниклары! Колхозлар һәм совхозлар сездән көндәлек квалификацияле ярдәм һәм җитәкчелек көтәләр, белемнәрегезне колхозчылар, совхоз һәм МТС эшчеләре белән уртаклашыгыз, аларны йөз пот уңыш алу өчен, социалистик терлекчелекнең чәчәк атуы өчен көрәшкә оештырыгыз.

Сталинчыл югары уңыш алу өчен көрәшкә бөтен көчне, бөтен җәмәгатьчелегебезне күтәрергә кирәк. Коммунистлар, комсомолецлар, авыл һәм район Советларының депутатлары йөз пот уңыш өчен ярышучыларның беренче сафларында булырга тиешләр. Колхозчылар һәм совхоз һәм МТС эшчеләре арасында агитация-масса эше киң колач алырга тиеш. Агитаторлар һәм беседачылар һәрбер бригадада һәм звенода ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларын, бөек Сталинның даһи күрсәтмәләрен, югары уңыш алучы ефремовчылар звеноларының һәм йөзпотчылар хәрәкәтенең политик һәм хуҗалык әһәмиятен аңлатырга тиешләр. Һәрбер уку өе һәм колхоз клубы югары уңыш өчен көрәштә алдынгы тәҗрибәне пропагандалауның үзәге булып әверелергә тиеш.

Безнең большевистик матбугат—өлкә һәм район газеталары, шулай ук колхозларның һәм бригадаларның стена газеталары зур роль уйнарга тиешләр. Газета битләрендә югары уңыш мастерларының тәҗрибәсен көн саен күрсәтә барырга, чәчүгә хәзерлекнең һәм чәчүнең барышын, агротехника чараларының үтәлешен яктыртырга кирәк. Матбугат йөз пот уңыш өчен, алдынгы агротехниканы кертү өчен социалистик ярыш оештыручы булырга тиеш. Һәрбер колхозчыда, һәрбер МТС һәм совхоз эшчесендә йөз пот уңыш яулап алуга тоткарсыз омтылыш тудырырга кирәк.

Кадерле иптәшләр!

1940 нчы елның 25 нче июнендә безнең орденлы республикабыз үзенең XX еллыгын бәйрәм итәчәк. Бу бәйрәмне производствода уңышлар белән истә калдыру—Татарстан хезмәт ияләренең намус эше. Без сезне ТАССР ның данлыклы XX еллыгын язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп хәзерләнү һәм аны яхшы итеп үткәрү белән, йөз пот уңыш өчен көрәштә хәл иткеч уңышлар белән каршыларга чакырабыз.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе, орденлы Татарстанның барлык хезмәт ияләре исеменнән, тугандаш республикалар белән—Чувашстан һәм Мордовия белән социалистик ярышка чыкты. Бу ярышта, Сталинчыл югары уңыш өчен, терлекчелекне үстерү өчен көрәш буенча үз өстенә зур җаваплы йөкләмә алды. Бу йөкләмәләрне намус белән үтәргә кирәк.

Иптәшләр, социалистик ярышка чыгыгыз, беренчелек өчен нығрак көрәшегез, кыенлыкларны кыюрак һәм кискенрәк җиңегез һәм җиңү тәэмин ителер. Югары уңыш өчен, социалистик терлекчелекнең чәчәк атуы өчен намуслы көрәш белән 1940 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашучылар санын арттырыйк.

Әйдәгез, иптәшләр, туганыбыз һәм сөекле атабыз, дустыбыз һәм остазыбыз Иосиф Виссарионович Сталин „Татарстан хезмәт ияләре яхшы эшлиләр!“ дип әйтерлек итеп эшлик.

Яшәсен социалистик Ватаныбыз!

Яшәсен җиңелмәслек Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе!

Яшәсен героик большевиклар партиясе!

Яшәсен юлбашчыбыз һәм остазыбыз, колхозчы крестьяннарның бөек дусты иптәш Сталин!

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе

1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ Е. Я. МАТВЕЕВ ДОКЛАДЫННАН

Иптәшләр! Сталинчыл бишьеллыклар елларында колхоз строе бик нык үсте һәм ныгыды. Социалистик авыл хужалыгы Советлар илендә эшләнгән һәм дөньяда иң яхшы булган машиналар белән коралландырылды. Үткән елны Татарстанның колхоз кырларында 5.410 трактор, 2.844 комбайн һәм башка төрле йөзләрчә катлаулы авыл хужалыгы машиналары эшләде. 1939 нчы елны гына да тракторлар һәм комбайннар паркы 17 процентка артты. Күп хезмәт куюны сорый торган кыр эшләренең яртысы диярлек машиналар белән эшләнде һәм бу хәл колхозларга агротехника чараларын киңрәк кулланырга мөмкинлек бирде.

Колхоз строеның данлыклы жиңүләренең йомгаклары 1939 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хужалыгы Күргәзмәсендә күрсәтелделәр. Күргәзмәдә Татарстаннан 457 колхоз, 119 терлекчелек фермасы, 2 МТС, 6 совхоз катнашты, шулай ук колхоз һәм совхоз производствосы алдынгыларыннан һәм аларны оештыручылардан 2.600 кеше катнашты. Республиканың иң яхшы 11 хужалыгы беренче дәрәжәле дипломнар һәм беренче премияләр, 53 хужалык икенче дәрәжәле дипломнар алуга ирештеләр. Буа районының Каганович исемендәге колхозы бөртекле культуралар буенча беренче дәрәжәле диплом һәм терлекчелек буенча икенче дәрәжәле диплом алды.

ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган тарихи докладында иптәш Сталин социалистик авыл хужалыгы алдына түбәндәге бурычны куйды: „Иң якындагы 3—4 ел эчендә гектарыннан уртача 12—13 центнер уңыш алып ел саен 8 миллиард пот ашлык житештерүгә ирешү өчен, техник культуралар житештерүне уртача 30—35 процентка арттыру өчен, сарыклар һәм дуңгызлар санын ике өлеш, мөгезле эре терлекләр санын 40 процент чамасына, атлар санын 35 процент чамасына арттыру өчен игенчелегебезнең һәм терлекчелегебезнең күтәрелүен тагын да жәелдерергә“.

Бу бурычны үтәү өчен көрәшеп, орденлы Татарстанның колхозчы крестьяннәре, большевиклар партиясе житәкчелегендә 1939 нчы елны яңа жиңүләргә ирештеләр. Һава шартларының начар булуына да карамастан, безнең күп кенә колхозларыбыз югары уңыш өчен, авыл хужалыгын тагын да күтәрү өчен көрәштә жидди уңышларга ирештеләр. Бу уңышлар—колхозчы крестьяннәр турында безнең коммунистлар партиясенең, бөек юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталинның көндәлек кайгыртучанлык күрсәтүләренең нәтижәсе.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының шушы елның январенда булган VIII нче пленумы 1939 нчы авыл хужалыгы елының йомгакларыннан төп нәтижәләрне ясады. Иң зур кимчелекләрнең берсе үткән елны республикабызның иген уңышы буенча дәүләт планын үтәмәвеннән, шулай ук трактор эшләре планын үтәмәвеннән гыйбарәт булганлыгы пленум карарында әйтелде. Һава шартлары начар булуга да карамастан, 1939 нчы елны без чынлыкта алганга караганда югарырак уңыш ала ала идекме? Һич шиксез, ала ала идек. Алдынгы колхозларның үрнәкләре моны ачык күрсәтәләр.

Әтнә районы, Ленин исемендәге колхоз башаклы культуралар буенча һәр гектардан уртача 84 пот уңыш жыеп алды, ә шул ук колхозның иптәш Ситдиков бригадасы гектарыннан 91 пот алды. 6 нчы бригада гектарыннан 116 пот арыш, 4 нче бригада гектарыннан 117 пот солы алды. Ленин исемендәге колхоз 1939 нчы елны күргәзмәдә катнашып, беренче дәрәжәле диплом, 10 мең сум акча һәм автомашина алды. Бу колхоз 1940 нчы елны да күргәзмәдә катнашу өчен кандидат. Шул ук колхозның күршесендә Куйбышев исемендәге колхоз бар. Аңа иптәш Жиһаншин житәкчелек итә. Барлык шартлар бер төрле булуга да карамастан, бу колхоз гектарыннан бары 54 пот кына бөртекле ашлык алган. Калинин районының „Чиялек“ колхозы (правление председателе иптәш Усманов) соңгы 3 ел эчендә гектарыннан уртача 85 пот бөртекле ашлык алды, ә аның белән янәшә, Кужәкә авылының иптәш Хажиев житәкчелегендәге колхоз бу еллар эчендә гектарыннан уртача бары 33 пот кына алган. Чаллы районының Чкалов исемендәге, Тельман районының Ленин исемендәге, Биектау районының Буденный исемендәге, Мамадыш районының „Хәсәнша“, Тәкәнеш районының „Новая Жизнь“ колхозлары һәм башка күп кенә колхозлар бөртекле культуралар буенча гектарыннан 90 пот һәм аннан да артыграк уңыш алдылар.

Иң яхшы кырчылык бригадалары һәм звенолар күп уңышларга ирештеләр. Мәсәлән, Норлат районы, „Кызыл Урманчы“ колхозының иптәш Сафин бригадасы гектарыннан 105 пот арпа, Чистай районы, „Дружба“ колхозының иптәш Ионычев бригадасы гектарыннан 96 пот бодай, 120 пот тары алды. Теләче районы, „Новая Жизнь“ колхозының иптәш Крысова звеносы гектарыннан 123 пот арыш, ә „КИМ“ совхозының 1938 нче елдан бирле эшләүче иптәш Горелова звеносы (звенода 5 кыз бар) гектарыннан 1.848 пот чөгендер алды. Бу совхозда гектарыннан уртача уңыш бары 270 пот кына.

Һава шартлары гаять дәрәжәдә начар булуга да карамастан, Норлат һәм Кызыл Юл районнары колхозлары бөртекле культураларны 1938 нче елга чагыштырганда 10 процент артыграк алдылар. Әтнә районы колхозлары да яхшы гына уңыш алдылар.

Алдынгы звеноларның, бригадаларның, колхозларның һәм совхозларның уңышка ирешүләре аларның агротехниканы киң күләмдә куллануылары белән (орлыкларны үрнәк булырлык итеп хәзерләүләре, туфракны яхшы итеп эшкәртүләре, ашламалар куллануылары, кар һәм язгы суларны тотулары белән) аңлатыла. Авыл хужалыгы эшләре барсы да вактында һәм югары сыйфатлы итеп үткәреләләр. Бу колхозларда хезмәт яхшы оештырылган; колхозчылар үзләренә тапшырылган эшне намус белән һәм чын күңелдән үтиләр, житәкчеләр һәм партия оешмалары кешеләр белән жидди рәвештә эшлиләр, колхоз производствосы турында кайгырталар, бөтен игтибарларын шуңа бирәләр.

Кызганычка каршы, Татарстанның күп кенә колхозларында бу нәрсә житеп бетми әле. Биләр, Әлки, Кызыл Армия һәм башка кайбер районнарның колхозлары үткән елны түбән уңыш алдылар. Моның төп сәбәбе шуннан гыйбарәт ки, район оешмалары һәм беренче чиратта район жир бүлекләре работниклары, МТС лар, колхоз правлениеләре алдынгы агротехниканы кертүдә, хезмәтне звенолап оештыруда әле аз эшләгәннәр. Монда Татнаркомзем тарафыннан да авыл хужалыгына йомшак житәкчелек ителү дә үзенең нәтижәсен күрсәтә.

„1939 нчы елны игеннәрне урыпжыюга һәм авыл хужалыгы продуктлары хәзерләүгә хәзерлек турында“ гы карарларында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы Татарстанда техник культуралар эшенең таркалганлыгын әйткәннәр иде. Үткән елга йомгак ясап без бу тармакта эшнең төзәлмәгәнлеген әйтергә тиешбез: республикада бу эш асылда өзелде. Кайбер колхозларны алмаганда, техник культуралар уңышы һаман да бик түбән әле.

Тканьның халык өчен нинди зур әһәмияте барлыгы, колхозларда киндергә булган сорауның никадәр зур икәнлеге һәр кемгә билгеле. Бу турыда районнарда бик күп сөйлиләр, ләкин аның белән эш жиңеләйми бит. Яхшы сүздән соң большевистик эш булырга тиеш, тик шулай булганда гына техник культуралар ягыннан хәлне тиз төзәтергә мөмкин булыр. Без моны бик тизлек белән эшләргә тиешбез. Сүз партия һәм хөкүмәт карарын үтәү турында, дәүләтебезнең, бөтен совет халкының төп интереслары турында барганлыкны аңларга кирәк.

Техник культуралар житештерүнең артта калуының сәбәпләре нәрсәдә соң? Алар шуннан гыйбарәт ки, бу культуралар берничә еллар буена әһәмияте аз булган, икенче дәрәжәдәге культуралар дип каралып киләләр. Татнаркомзем һәм аның түбәнге буыннары, шулай ук районнарның житәкче оешмалары бу зур һәм әһәмиятле эш белән күңел биреп шөгыльләнмәделәр. Күп кенә колхозларда техник культураларга иң начар жирләрне бирәләр, аларны бик соңга калып чәчәләр, аларны тиешенчә тәрбияләүне оештырмыйлар, алдынгы агротехникадан файдаланмыйлар. Техник культураларга жинаят төсендә карау фактлары бар. Мәсәлән, Минзәлә районының „Луговой“ колхозында 1937 нче елдан бирле орлыгы сугылмаган житен ята, Азнакай районының „Кызыл Байрак“ колхозында үткән елгы бөтен киндер саламын ындырда черткәннәр, дәүләткә бер килограмм да сүс тапшырмаганнар. Бөгелмә районының „Новый Путь“ колхозында сугылмаган киндер саламы белән терлек сараен япканнар. Мондый фактлар белән килешергә мөмкин түгел.

Безнең республикада техник культураларны ничек житештерергә кирәклекне күрсәтә торган яхшы үрнәкләр дә аз түгел. Акташ районының „Восход“ колхозы 1938 нче елны киндердән 55 мең сум доход алган. Үткән елны анда 20 гектар киндер чәчелгән һәм гектарыннан 5,5 центнер сүс уңышы алынган. Дәүләткә киндер продукциясе тапшырудан колхоз 60 мең сум чамасы доход алган. Шул ук районның Чумаков исемендәге колхозда иптәш Домнина звеносы үткән елны 4,5 гектарлык мәйданның һәр гектарыннан 7 центнер сүс алган. Шөгер районының „Партизан“ колхозы (правление председателе иптәш Сәмигуллин) гектарыннан 7,8 центнер киндер сүсе һәм 5 центнер орлык алган. Монда бу уңышны житәкчеләрнең һәм колхозчыларның техник культураларга тиешенчә бәя бирүләре, агротехника чараларын киң куллануылары, житен һәм киндерне игтибар белән үстерүләре аркасында алганнар. 1939 нчы елны „Партизан“ колхозында киндер чәчелгән бөтен мәйдан гектарына 35 тонна исәбеннән тирес белән ашланган. Чәчүлекләрнең биштән бер өлеше тирес сыекчасы белән туклandырылган, киндерне жентекләп тәрбияләү оештырылган һәм уңыш үз вактында һәм югалтусыз жыеп алынган, контрактация договоры буенча дәүләт йөкләмәләрен вактында үтәгәннән соң бу колхоз әле һаман да дәүләткә киндер тапшыруын дәвам иттерә. Киндер тапшырудан гына да ул 50 мең сум доход алган, шулардан 25 мең сумы премияләр һәм өстәмә түләүләр.

Бу мисалләр һәрбер колхозның техник культуралардан ел саен югары уңыш алырга мөмкинлеге барлыкны күрсәтәләр. Тик бу эшкә житәкчеләрнең, жир системасы работникларының, партия оешмаларының үзләренең карашларын үзгәртүләре генә кирәк. Житен һәм киндер иң яхшы жирләргә чәчелергә һәм үзләре өчен иң яхшы булган элгәрләр артыннан чәчелергә тиеш. Техник культуралар чәчеләсе жирләрне тирес һәм минераль ашламалар, шулай ук көл белән бик жентекләп ашларга кирәк. Алдынгы колхозлардан үрнәк алып, техник культуралар чәчүлекләрен даими звеноларга беркетергә һәм аларга житәкчелеккә иң тәжрибәле кешеләрне куярга, колхозчылар арасында агротехниканы өйрәнүне оештырырга, колхоз производствосының бу жаваплы тармагында эшләүче кешеләрнең махсус киңәшмәләрен чакырырга кирәк. Югары уңыш алу өчен звенолар арасында һәм звенолар эчендә социалистик ярышны жәелдерергә, алдынгы колхозларның тәжрибәләрен матбугатта яктыртырга, ефремовчыларның казанышларын киң күләмдә пропагандаларга кирәк.

Безнең бурычыбыз—Татарстанның техник культуралар житештерү буенча алдынгы өлкәләр һәм республикалар сафында булуы өчен, гектарыннан кимендә 4,6 центнер житен сүсе алу турында ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарын тизрәк үтәү өчен бөтенесен эшләү.

МТС ҺӘМ СОВХОЗЛАРНЫҢ МАШИНА-ТРАКТОР ПАРКЫННАН ФАЙДАЛАНУ

Машина-трактор станцияләренең эшен тагын да яхшыртуга партия һәм хөкүмәт гаять зур игтибар бирәләр. Моның өчен соңгы ике ел эчендә генә дә ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы күп кенә карарлар кабул иттеләр.

МТС ларның колхозлар белән яңа үрнәк договоры расланды. МТС лар барлык авыл хужалыгы эшләрен үткәрүнең срокларын һәм сыйфат күрсәткечләрен төгәл үтәргә тиешләр. Колхоз правлениеләренә тракторчылардан эшне бик нык кабул итеп алырга һәм брак табылган хәлләрдә бик тизлек белән акт төзергә һәм бу актларны район башкарма комитетлары карамагына бирергә тәкъдим ителде. Тырмалауны, культивацияләүне һәм чәчүне кыска срокларда үткәрү белән тракторчыларны һәм колхозчыларны кызыксындыру өчен хезмәткә түләүдә өстәмәләр кертелде, шулай ук язгы эшләрнең беренче көннәрендә ягулык расходы нормалары арттырылды. ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының 1939 нчы ел 13 нче январь карары буенча, тракторчыларга, бригадирларга һәм аларның ярдәмчеләренә акчалата гарантия минимумы түләү билгеләнде. МТС ларда тракторчыларның эш нормалары һәм эш бәяләре расланды, сменада эш нормасын үтәгән өчен түләү кертелде һәм смена нормасын арттырып үтәгән өчен трактор эшләренең барлык төрләре буенча прогрессив түләү билгеләнде. Комбайнчыларга эш нормаларыннан тыш бер көн эчендә сугылган ашлык өчен өстәмә бәя—премия билгеләнде. Люцерна орлыклык участкыларын урып-жыюда эшләүче комбайнчыларның эш бәяләре, шулай ук житен йолку, житен талку, киндер урып-жыю машиналарында һәм катлаулы житен молотилкаларында эшләүче машинистларның эш бәяләре арттырылды.

Партиянең һәм хөкүмәтнең бу чаралары барсы да тракторчыларның, комбайнчыларның, механикларның, машинистларның һәм башка авыл хужалыгы белгечләренең производство һәм политик активлыклары әлегәчә булмаган дәрәжәдә күтәрелүдә чагылды. Шушы нигездә, большевистик житәкчелек тәэмин ителгән МТС ларның барсында да бик яхшы нәтижәләргә ирешелде. Мәсәлән, Актаныш МТС ы 15 ат көчле бер трактор белән уртача 989 гектар эшләп, трактор эшләре планын 117,6 процент итеп үтәгән, Теләнче Тамак МТС ы бер трактор белән 855 гектар сөреп, 117,8 процент үтәгән. Нөркәй, Сарман, Тымытык һәм Столбище машина-трактор станцияләре алардан бик аз гына калышканнар.

Актаныш һәм Октябрь МТС лары күргәзмәдә беренче дәрәжәле диплом алуга ирештеләр һәм аларның һәрберсе жиңел машина һәм 10 мең сум акча белән бүләкләнде. Машина-трактор паркыннан яхшы файдаланган өчен, дәүләт планнарын арттырып үтәгән өчен, ягу һәм майлау материалларына экономия ясаган өчен һәм машиналарга ремонт ясаганда сумаларны саклап тотканы өчен Татнаркомзем Нөркәй, Теләнче Тамак, Сарман һәм Базарлы Матак МТС ларын бүләкләде.

Алдынгы МТС ларның эшендә иң күренекле як булып, житәкчелекнең кешеләр турында көндәлек кайгыртучанлыгы, тракторларны һәм комбайннарны техник яктан карап торуның юлга салынган булуы, тракторчылар, комбайнчылар һәм башка работниклар арасында социалистик ярышның яхшы куелган булуы тора. МТС ларның кадрлары даими. Актаныш МТС ында 7 бригадир, 35 тракторчы, 12 комбайнчы 5 елдан артык эшләп киләләр. Прицепщикларның, су һәм ягулык ташучыларның күпчелеге 2 елдан 5 елга кадәр алмашсыз эшләп киләләр, алар бер үк машиналарга һәм бригадаларга хезмәт күрсәтәләр. Тракторчылар һәм комбайнчылар үзләренә беркетелгән машиналарда озак вакыт эшлиләр.

Республикабызның йөзләрчә иң яхшы тракторчылары, бригадирлары һәм комбайнчылары үткән елны үзләренә беркетелгән машиналарда рекордлы күрсәткечләр бирүгә ирештеләр. Менә, мәсәлән, Актаныш МТС ының Әһли Әглямов бригадасы: күпчәкле бер трактор белән ул 1.390 гектар эшләгән, шул ук МТС ның орденлы Гыйлми Хафизов бригадасы 1.150 гектар эшләгән. Нөркәй МТС ында Жиһангир Фәхриев, Галиәхмәт Галиев һәм Вәли Салахов, Тымытык МТС ында Фәридә Зарипова һәм Зәкия Кәримова, Арча МТС ында Жәббар Сафин, Азин МТС ында Шакиров иптәшләр бригадалары машиналардан большевикларча, оста файдалану үрнәкләре күрсәттеләр. Тымытык МТС ы комбайнчысы М. Дәүләтшин иптәш „Коммунар“ комбайны белән 985 гектар, Иске Тимошкино МТС ында иптәш Павлов, Сарман МТС ында Гафиятуллин һәм Тюфяков иптәшләр 700 гектардан артык урып-жыйганнар. Уннарча алдынгы тракторчылар үз сменаларында 1,5 норма һәм аннан да артык үтәделәр.

СТЗ—НАТИ тракторларында Сәубан Фәттахов үз сменасында 1.260 гектар, Алексей Репин 1.244 гектар эшләгәннәр һәм ягулыкка бик күп экономия ясаганнар. Бик яхшы эшләү һәм машиналардан үрнәк булырлык файдалану үрнәкләрен бик күп китерергә мөмкин.

1939 нчы елны гомумән Татарстанда трактор эшләре планының үтәлмәве исә бездә әле күп кенә артта калучы МТС лар барлыктан килеп чыга. Планны 31,7 процентка гына үтәгән Юртыш МТС ы, 40,7 процент үтәгән Зөя МТС ы, 55,3 процент үтәгән Юдино МТС ы, 49,3 процентка үтәгән Кызыл Чапчак МТС ы республикада артта баралар. Монда барыннан да элек МТС житәкчеләре гаепле, алар эшкә салкын караганнар һәм тракторлар паркыннан файдалануда жавапсызлык күрсәткәннәр. Монда тракторчыларның эшләре тиешенчә оештырылмаган, ныклы хезмәт дисциплинасы булмаган һәм машиналар еш кына эшсез торганнар.

ҖӘМАГАТ ТЕРЛЕКЧЕЛЕГЕН БАРЛЫК ЧАРАЛАР БЕЛӘН ҮСТЕРЕРГӘ

Шушы елның январена үткәрелгән терлекчелек санын алу үткән ел белән чагыштырганда колхоз фермаларында мөгезле эре терлекләрнең саны 16,7 процент, сарыклар саны 27,9 процент, кәжәләр саны 110,5 процент һәм атлар саны 17,2 процент үсканлекне күрсәтте.

Республикада яңадан 2.656 терлекчелек фермасы оештырылды. Хәзер Татарстан колхозларында 9.037 терлекчелек фермасы бар. Шуның өстенә колхозларда 384 йорт куяннары фермасы һәм 174 кошчылык фермасы бар.

Терлекчелекне тагын да үстерү өчен көрәштә алдынгы колхозлардан Чаллы районының „Ташкичү“ колхозы (председателе иптәш Галимов) товарлыклы - сөтчелек фермасына терлекләр туплау планын гомумән 121 процент итеп, ана терлекләр буенча 100 процент итеп һәм яш терлекләр үстерү буенча 128 процент итеп үтәгән. Бу колхозда дәүләт йөкләмәләре күптән үтәлгәннәр. Норлат районының Ленин исемендәге колхозы (председателе иптәш Гайнуллин) мөгезле эре терлекләр планын 100,2 процент һәм сарыклар буенча 100,1 процент итеп үтәгән.

Юдино районының „Яңа Тормыш“ колхозы (председателе иптәш Вәлиев) терлекчелекне үстерү планын һәм дәүләт йөкләмәләрен үтәгән. Үткән елны бу колхоз терлекчелектән 75 мең сум доход алган. Бер сыерның еллык уртача сөт биреше 1.800 литрга житкән, ягни 1938 нче елга чагыштырганда ике тапкыр булган.

Казан Зооветинституты профессоры иптәш Сырневның һәм аның житәкчелегендәге кафедра сотрудникларының 1938—1939 нчы елларда „Яңа Тормыш“ колхозында зур эш үткәргәнлекләрен әйтергә кирәк. Алар ярдәме белән колхозда ферманың 1940 нчы елгы производство планы төзелгән. Планда һәрбер сыердан кимендә 2.500 литр сөт алу күздә тотылган. Профессор Сырнев инициативасы буенча Юдино районында терлекчелек алдынгылары киңәшмәсе үткәрелгән.

Республикабызның колхозларында бик яхшы кешеләр, терлекчелек алдынгылары бар. Алардан өйрәнергә мөмкин һәм кирәк. Яңа Писмән районының „Уңыш“ колхозында көтүче Мәхмүт Әюпов соңгы ике ел эчендә һәр 100 сарыктан уртача 160 бәрән һәм бер сарыктан уртача 3,38 килограмм йон алган, Кайбыч районы, „Активист“ колхозында фатыйма Гыймадова үз карамагындагы һәрбер сыердан 2.556 литр сөт алган. Совхозларыбызда да күп кенә терлекчелек алдынгылары бар. „КИМ“ совхозында терлекчелек бригадасы бригадиры Евдокия Яковлевна Медведева танылган кешеләрнең берсе. Иптәш Медведева анда 12 ел эшли, аның бригадасында 100 сыер бар. Үткән елны ул һәрбер сыердан 3.689 литр сөт алган. Шул ук совхозның сыер сауучысы Анна Яковлевна Барышева үз карамагындагы сыерларның һәрберсеннән 4.180 литр сөт алган, ә „Лия“ сыерыннан—10.000 литр. Бозау караучы Анастасия Куприяновна Пыркова бозауларның үлчәвен тәүлегенә уртача 833 граммга арттырып килгән, бозау караучы Степанида Васильевна Соловьева һәм сыер сауучы Анастасия Задворнова Кулай совхозында бик яхшы эшлиләр.

Ләкин алдынгыларның гына уңышлары безне һич тә тынычландыра алмыйлар һәм тынычландырмаска тиешләр. Гомумән алганда республикада терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планы 1939 нчы елны үтәлмәде. Шулай ук яңа фермалар оештыру һәм моннан элек яшәп килгән вак фермаларга терлекләр туплау планы да үтәлмәде. Питрәч районы товарлыклы - сөтчелек фермалары оештыру планын бары 51,7 процентка гына, аларга терлекләр туплау планын 10,4 процентка гына үтәгән.

Биләр районында товарлыклы сөтчелек фермалары оештыру планы бары 72 процентка гына, аларга терлекләр туплау планы 29,2 процентка гына үтәлгән. Соңгы вакытларда яңа оештырылган фермаларга тагын да терлекләр туплау һәм иске фермаларны киңәйтү эше туктатылган.

Республикабызның колхозларына партия һәм хөкүмәт зур ярдәм күрсәтәләр. 1939 нчы елны терлекчелек чараларына 8 миллион 279 мең сум кредит жибәрелде. Бездә терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планын үтәү өчен генә түгел, бәлки арттырып үтәү өчен дә бөтен мөмкинлекләр бар. Тик барлык кредитлардан файдаланырга, терлекләр сатып алуга колхозларның үз сумаларын тартырга гына кирәк. Шул ук вакытта колхозларда һәм совхозларда барлык терлекләрне саклау һәм аларның продукт бирүләрен күтәрү өчен кискен көрәш алып барырга кирәк.

Республикабызның алдынгы колхозлары 1939 нчы елгы барлык авыл хужалыгы эшләрен уңышлы төгәлләп, дәүләт йөкләмәләрен срогыннан алда үтәп, орлыкларны туплап, хәзер колхозчылар арасында доход бүләләр. Бу колхозларда хезмәт көннәренә югары бәя бирелә. Мәсәлән, Биектау районы, Буденный исемендәге колхозның колхозчылары бер хезмәт көненә 5,5 килограмм ашлык, 6,9 килограмм яшелчә һәм 1 сум 60 тиен акча алалар. Анда хезмәткә яраклы барлык колхозчылар билгеләнгән хезмәт көннәре минимумын шактый арттырып үтәгәннәр. Мамадыш районының „Игенче“ колхозында һәм Красный Бор районының „Кызыл Йолдыз“ колхозында бер хезмәт көненә 5,5 килограмм ашлык туры килә.

Югары Ослан районының Дзержинский исемендәге колхозында Андреев семьясе 1.124 хезмәт көне эшләгән һәм 5.765 сум акча, 1.686 килограмм ашлык, 1.573 килограмм алма, 3.034 кило яшелчә һәм 3.300 килограмм фураж ала. Петров семьясе 5.700 сум акча, 1.700 килограмм ашлык, 1.588 килограмм алма, 3.036 килограмм яшелчә һәм 3.300 килограмм фураж ала. Бу колхозда бер хезмәт көненә уртача 4 сум 64 тиен туры килә, 1938 нче елны 2 сум 50 тиен иде. Ворошилов исемендәге колхозда (Югары Ослан районы) ат караучы иптәш Обмелихин 5.184 сум акча һәм 111 пот ашлык ала. Теләче районы, „Кызыл Ямбулат“ авыл хужалыгы артеле члены иптәш Сөләйманов үзенең хезмәт көннәренә 262 пот, иптәш Гыйлажов 269 пот ашлык алалар.

Кем яхшы эшләгән булса, шул кеше яхшырак ала. Һәм „Әгәр дә күпчелек кенә түгел, бәлки барлык колхозчыларда намус белән эшләсәләр, колхозлар продуктлар белән тулырлар, алар һәр төрле байлык белән тулырлар һәм илебез дөньяда иң бай булып әверелер“ (Сталин). Халыкларыбыз юлбашчысының бу күрсәтмәсен һәрбер колхозда ныклык белән тормышка үткәрергә кирәк.

(Ахры 3 нче биттә).

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе

1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ Е. Я. МАТВЕЕВ ДОКЛАДЫННАН

(Башы 2 нче биттә).

Доходларны бүлү турында сөйләгәндә күп кенә колхозларда бу эшнең һәм еллык отчетлар төзүнең чиктән тыш акрын, оешмаган тестә баруын күрсәтергә кирәк. Бу әһәмиятле эшкә Татнаркомзем, район җир бүлекләре, МТС лар һәм районнарның башка оешмалары бик начар җитәкчелек итәләр. Колхозларда доход бүлү белән якыннан торып шөгыльләнергә һәм аны авыл хуҗалыгы артеле уставына нык туры китереп үткәрергә кирәк.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮНЕ БОЛЬШЕВИКЛАРЧА КАРШЫЛАРГА ҺӘМ ҮТКӘРЕРГӘ

1940 нчы елны без гектарыннан кимендә 13 центнер бөртекле ашлык алырга тиешбез. Моның өчен барлык авыл хуҗалыгы эшләрен үрнәк булырлык итеп үткәрүне тәэмин итәргә кирәк. Ләкин бездә чәчүгә хәзерлек кәнагатьләнерлек түгел. Тракторларга ремонт ясау планы 20 нче январьга 39,6 процентка гына үтәлгән.

Тракторларга ремонт ясауны хәзергә әле Нөркәй, Теләче, Тымытык, Маткавыш МТС лары гына уңышлы башкарганнар. Күпчелек МТС лар исә тракторларны хәзерләүне гафу ителмәслек озакка сузалар. Дмитров, Кукмара, Кызыл Йолдыз һәм Үзәк МТС лары аеруча артта калалар. Зөя МТС ында әле хәзергә кадәр бер трактор да ремонттан үтмәгән.

Тикшерүләр тракторларга ремонтның югары сыйфаты турында күп кенә МТС җитәкчеләренең кайгыртмауларын күрсәтә. Мәсәлән, Үзәк МТС ында (директоры иптәш Газизов) ремонт ясалган 3 тракторның маховиклары начар беркетелгән, һава чистарткычлары юылмаган, һава шлангысының хомутиклары юк, руле җайланмаган булып чыкты. Бу машиналар барсы да яңадан ремонтка куелдылар.

Алга МТС ында (директоры иптәш Бәдреттинев) һәм Чистай МТС ында да шундый фактлар табылды. Чистай МТМ ы Яңа Чишмә МТС ы өчен 10 трактор моторына ремонт ясап биргән һәм алар барсы да кабул иткән вакытта бракка чыгарылганнар.

Механизаторлар кадрлары хәзерләү эше гаять начар тора. 10 нчы январьга „СТЗ-НАТИ" тракторчылары курсларына укучылар туплау планының 46 процентка, газогенераторлы тракторлар буенча 22 процентка, „ЧТЗ—60" тракторлары буенча 13,5 процентка, комбайнчылар курсларына 66 процентка һәм комбайнчы ярдәмчеләре курсларына 38,5 процент кына үтәлгән. Кичү МТС комбайнчыларны бөтенләй хәзерләми, тракторчылар курсына кеше җибәрми. Шунда ук МТС янындагы тракторчылар курсына укучылар туплау планы да үтәлмәгән, шунын өстенә укырга алынган 32 кеше арасында хатын-кызлар бары 8 кеше генә. Куйбышев, Беренче Май МТС ында, башка МТС ларда һәм совхозларда да шундый ук хәл.

Орлыклар туплау, аларны чистарту һәм сыйфатын тикшерү бик акрын бара. Әлки, Биләр, Кызыл Армия, Яңа Чишмә һәм кайбер башка районнар аеруча артта калалар. Күп еллык үлән (клевер һәм люцерна) орлыклары тупланмаган. Клевер чәчү буенча дәүләт планын үтәү өчен орлыклар бары 7,8 процент кына, люцерна буенча 55,4 процент кына. Шул ук вакытта Кукмара, Балык Бистәсе, Алексеевский һәм башка кайбер районнарда үткән елгы клевер һәм люцерна сугылып бетмәгән.

Күп кенә районнарда кышкы агротехника чаралары: тирес чыгару, кар тоту, көл җыю, минераль ашламалар ташу кебек эшләр планы начар үтәлә. Тәмте, Кама Тамагы һәм Юдино районнарында бу эш башланмаган. Югары Ослан районында кар тоту бары 760 гектар, Тәмте районында 1.081 гектар мәйданда гына үткәрелгән. Бу районнарда тирес чыгаруны һәм башка төрле җирле ашламалар җыюны ашыктырмыйлар һ. б. Бу районнарның артта калуын бары тик җитәкчеләрнең, җир бүлекләре һәм МТС работникларының гамсезлеге белән генә аңлатырга мөмкин. Октябрь районында кар тотуны 19.406 гектар мәйданда, Буденный районында 13.316 гектарда, Ютазы районында 12.171 гектарда үткәрә алганнар бит. Тымытык районы колхозлары кырларга инде 120.000 йөк, Актаныш районы 141.100 йөк һәм Тәкәнеш районы 95.000 йөк тирес чыгарганнар.

Югары уңыш өчен көрәштә колхозчыларның агротехниканы өйрәнүләренең зур әһәмияте бар. Тулы булмаган саннарга караганда, Татарстан районнарында 300 дән артык стахановчылар мәктәпләре һәм 3.196 агрономия түгәрәкләре оештырылган, аларда 63.000 нән артык кеше укый. Минзәлә районында 12 стахановчылар мәктәбе һәм 161 агрономия түгәрәге эшләп килә. Аларда 3.033 колхозчы укый. Монда колхозчыларның агрономияне өйрәнүләрен оештыруда район җир бүлегенең өлкән агрономы иптәш Ерашов зур инициатива күрсәтә. Норлат, Мөслим һәм Калинин районнарында уку яхшы оештырылган. Ләкин күп кенә районнарда түгәрәкләр җае туры килгәндә генә эшлиләр, ә кайберләре кәгаздә генә саналалар. Питрәч районында бары бер стахановчылар мәктәбе һәм 24 түгәрәк, Мамадыш районында 1 мәктәп, 47 түгәрәк һәм Яңа Писмән районында 1 мәктәп һәм 41 түгәрәк оештырылган. Түгәрәкләрнең эшен җайга салуда аерым белгечләр, район җир бүлекләренең һәм МТС ларның работниклары колхозларга кирәкле ярдәмне күрсәтмиләр. Татнаркомзем да бу турыда аз кайгырта. Татнаркомзем һәм Татгосиздат әле һаман да колхозларны 1940 нчы елга агрономия кагыйдәләре белән тәэмин итмәгәннәр.

Язгы чәчүгә хәзерлек уңае белән безнең бурычларыбыз нәрсәләрдән гыйбарәт? Бу турыда ВКП(б) Өлкә Комитетының январь пленумының „1940 нчы елгы язгы чәчүгә хәзерлек турында" гы карарында ачык әйтелгән. Бу карарны барлык колхозчыларга, совхозлардагы һәм МТС лардагы эшчеләргә җиткерергә, аны гомуми җыелышларда киң күләмдә тикшерергә һәм язга үрнәк булырлык итеп хәзерләнү өчен көрәшкә массаны оештырырга кирәк.

1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы эшләренең дәүләт планы районнарга һәм колхозларга җиткерелде инде. Бу план буенча быел бөртекле ашлык гектарыннан кимендә 12 центнер, тары 9, кара бодай 7,7, көнбагыш 7,5, долгунец җитен сүсе 2,8, кудряш җитен орлыгы 3,8 һәм киндер сүсе 3,5 центнер алынырга тиеш.

Бу заданиене без үтәп кенә калмыйча арттырып та үтәргә тиешбез. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар.

Быел бездә 900 гектар бакча һәм 250 гектар җиләклек булдырырга туры киләчәк. Бу гаять зур һәм җидди эш. Иң якын елларда һәрбер колхозның һәм совхозның бакчалары һәм җиләклекләре, һәрбер колхозчы йортының үзенең бакчасы булуга ирешергә кирәк.

„Колхозларда бөртекле культуралар чәчүлекләрен планлаштыру турында" һәм „колхозларда бөртекле культураларның сортлы чәчүлекләрен планлаштыру турында" СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарларының гаять зур әһәмияте бар. Бу карарлар иген уңышын тагын да һәм тизрәк күтәрергә, бу эштә колхозчыларның инициативаларын үстерүгә юнәлдерелгән. Җир органнары бу карарларны тормышка үткәрүне тәэмин итәргә, сортлы чәчүлекләр планын үтәүгә ирешергә, иң яхшы сортлы орлыклардан иң күп күләмдә файдалануга ирешергә тиешләр.

Татарстан МТС лары өчен трактор эшләре планы 4 миллион 555 мең гектар күләмендә итеп расланды, 15 ат көчле бер трактор белән 590 гектар һәм һәрбер комбайн белән 280 гектар эшләргә задание бирелде. Бу план үтәлә ала һәм үтәлергә тиеш. Тик ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы билгеләгән сроктан да соңга калмыйча, тракторларга ремонтны тулысынча һәм бик яхшы итеп тәгәлләргә, механизаторлар кадрлары хәзерләү планын үтәргә, курсларга хатын-кызларны иң күп күләмдә тартырга, ягулыкны вактында китерергә кирәк һәм трактор отрядларын, даими составтагы квалификацияле прицепщиклар белән тәэмин итәргә кирәк. Прицепщиклар барсы да һәрбер МТС янында махсус оештырылган 3—5 көнлек курслар аркылы үткәрелергә тиеш. Эшләрнең күләмен, нинди сыйфатлы булырга тиешлекне һәм үтәү срокларын күрсәтеп, эш планын һәрбер трактор бригадасына алдан ук җиткерергә, тракторчыларны культуралы итеп җиһазландырылган вагоннар белән тәэмин итәргә, отрядларда агротехниканы өйрәнүне оештырырга кирәк.

Икенче яктан, кыр һәм трактор бригадаларының эшен шундый итеп оештырырга кирәк ки, алар иген уңышын күтәрү өчен бергәләшеп көрәшә алырлык булсыннар. Кырда эшләячәк кешеләр өчен барлык кирәк нәрсәләрне хәзер үк хәзерләп куярга кирәк. Язгы чәчүне иң кыска срокларда һәм югары агротехника дәрәҗәсендә үткәрү, иртә культураларны кимендә 7—8 көн эчендә чәчеп бетерү өчен җәмагат туклануын, культура хезмәте күрсәтүне, кыр станнарын, вагоннарны һәм башкаларны яхшы итеп хәзерләргә кирәк.

Аннары без барлык тракторлардан, шул җөмләдән моннан элек яраксыз дип исәптән чыгарылган тракторлардан тулысынча файдалану өчен барлык чараларны күрергә тиешбез. Газогенераторлы тракторлардан файдалануга аеруча игтибар бирергә, аларны кадрлар белән тәэмин итәргә һәм алар өчен алдан ук ягулык хәзерләп куярга кирәк.

МТС һәм совхоз тракторлары башкара торган эшләрнең сыйфаты өчен МТС директорларының район җир бүлекләре мөдирләренең һәм бөтен агрономия персоналының җаваплылыгын күтәрергә, тирән сөрүгә ирешергә, предплужниклардан тулысынча файдаланырга, чәчү алдындагы, чәчү вактындагы, урып-җыю вактындагы һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшләренең барсының да сыйфатын яхшыртырга кирәк. Колхоз җитәкчеләренең, авыл хуҗалыгы белгечләренең, район оешмаларының брак эшләүче тракторчыларга юл куюлары һичтә гафу ителерлек хәл түгел.

Алдынгы колхозларның һәм совхозларның тәҗрибәсе, хезмәтне бригада эчендә оештыруның иң яраклы төп формасы даими звено икәнлекне җитәрлек кадәр ачык күрсәтә. Хезмәтне болай оештыру методына ВКП(б) ның XVIII нче съезды югары бәя бирде. Даими звенолар төзелү белән колхозларда иясезлек бетерелә һәм хезмәт җитештерүчәнлеге күтәрелә. Даими звено югары уңыш өчен, колхозларны тагын да ныгыту һәм үстерү өчен көрәшкә колхозчылар массасын туплауның иң яхшы юлларыннан берсе һәм без Татарстанның барлык колхозларында да хезмәтне звенолап оештыруны кертергә тиешбез.

Бөртекле, техник һәм яшелчә культуралары орлыкларын, шулай ук үлән орлыкларын һәм орлыклык бәрәңгене тизрәк тупларга, аларны чәчү кондицияләренә җиткерергә кирәк. Якын араларда ук гади орлыкларны колхозлар арасында сортлы орлыкларга алмашуны тәгәлләргә, барлык орлыкларны бик нык саклауны оештырырга кирәк.

Югары уңыш өчен көрәштә кар тотуның зур әһәмияте бар. Дым өчен көрәш—югары уңыш өчен көрәш ул. Тәҗрибә станцияләре һәм авыл хуҗалыгы алдынгылары тәҗрибәсе күрсәткәнчә, һәрбер гектарда тотылган 1 сантиметр тирәнлектәге кар 6—9 пот өстәмә уңыш бирә. Кар тоту планы югары сыйфатлы итеп үтәлергә тиеш, шулай ук кырларны саклаучы урман полосалары утырту планы да үтәлергә тиеш. Кар суларын тотуга хәзерлекне хәзер үк башлап җибәрергә кирәк.

Җирле ашламалар җыю, кырга тирес чыгару эшен шактый көчәйтергә, минераль ашламалар кертүне тизләтергә кирәк. Атны үрнәк булырлык итеп хәзерләргә, аны бик яхшы тәрбияләүне тәэмин итәргә, транспортны һәм сбруйларны хәзерләп куярга, бөтен вак төякләрне алдан күрергә кирәк.

Колхоз лабораторияләренә иң җидди игтибар бирелергә тиеш. Алар Татарстанда 500 дән артык, ләкин кайбер районнарда, мәсәлән, Яңа Чишмә районында бер генә лаборатория дә юк. Колхоз лабораторияләре бөтен алдынгы тәҗрибәне оештыручы чын үзәк булырга һәм аны колхозлар практикасына үткәрүдә ярдәм итәргә тиешләр.

Колхозлар һәм совхозлар безнең фәнни һәм тәҗрибә учреждениеләребездән эшлекле, конкрет ярдәм көтәләр. Авыл Хуҗалыгы институты, тәҗрибә станциясе, университет һәм техникум работниклары 100 пот уңыш өчен көрәшкә чын-чынлап кушылырга тиешләр.

Шулай ук безнең республикабызның 1940 нчы елгы күргәзмәгә хәзерлеге канәгатьләнерлек түгеллекне дә әйтергә кирәк. Татнаркомземга колхозлардан, МТС лардан һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан бары 2.229 гариза кергән. 300 гариза биргән Сарман районы һәм 234 гариза биргән Актаныш районы барыннан да алда баралар. Ләкин менә Кызыл Армия, Тәмте, Юдино һәм Чепья районнары бер генә гариза да бирмәгәннәр. Татсовхозтрест һәм Спирттрест совхозларыннан да бер гариза да кермәгән. Эштәге бу зур кимчелекне бетерү өчен Татнаркомзем, Совхозтрест һәм районнарның җитәкче оешмалары барлык чараларны күрергә тиешләр.

„Колхозларның җәмагат җирләрен әрәм-шәрәм итүдән саклау чаралары турында" ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карары нигезендә республикабыз колхозларында хезмәт дисциплинасы шактый яхшырды, ләкин кайбер урыннарда әле җәмагат эшләреннән баш тартучы, колхозларда намус белән эшләргә теләмәүче һәм шуның белән авыл хуҗалыгы артеле уставын бозучы кешеләр бар. Колхозларда хезмәт дисциплинасын барлык чаралар белән һәм тагын да ныгытырга кирәк.

Язга бик яхшы хәзерләнү, чәчүне һәм барлык авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы үткәрү, йөзпотчыларның Бөтенсоюз ярышында беренче урыннарның берсен яулап алу өчен безгә барлык МТС ларда, совхозларда, колхозларда, бригадаларда, звеноларда, массовый-политик эшне киң җәелдерергә кирәк. Бу эштә партия, комсомол, совет оешмалары өлкә һәм район газеталары җитәкче, оештыручы роль уйнарга тиешләр.

1940 нчы елны безгә иген уңышы планын, социалистик терлекчелекне үстерү планын үтәрлек итеп кенә түгел, бәлки арттырып үтәрлек итеп тә эшләргә кирәк һәм шуның белән ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларын һәм халыклар юлбашчысы иптәш Сталин күрсәтмәләрен үтәүне тизләтергә кирәк. (Кул чабулар).

Быел Татарстан АССР ның яшәвенә XX ел тула. Бу данлыклы датаны социалистик ярышның киң җәелүе белән, стахановча эшләү белән, авыл хуҗалыгының барлык тармакларында да яңа җиңүләр белән каршы алыйк.

Яшәсен социалистик Ватаныбыз!

Яшәсен бөек Совет халкы!

Яшәсен ВКП(б)!

Яшәсен бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы һәм остазы, туганыбыз бөек Сталин! (Озакка сузылган кул чабулар).

Татарстан АССР ның егерме еллыгына хәзерлекне киң җәелдерик

Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе

Данлыклы тарихи дата—Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасының 20 еллыгы якынлаша. Социалистик Татарстанның яшәве—улЛенин—Сталин милли политикасы тантанасының иң ачык күрсәткечләреннән берсе.

Элек царизм тарафыннан ачлыкка, культурасызлыкка һәм үлеп бетүгә дучар ителгән, изелгән, кимсетелгән ярым колониаль татар халкына 1917 нче елгы бөек пролетар революция экономик һәм культура ягыннан алга китү өчен, иҗади көчләрнең куәтле чәчәк атуы өчен киң юл ачты.

Яши башлавының беренче көннәрендә үк Совет власте тынычлык, җир турындагы, производствога эшчеләр контроле турындагы декретлар белән бергә, Россия халыклары хокукларының декларациясен иглан итте. Гражданнар сугышы фронтларында орудие тавышлары басылып та өлгермәгән иде әле, яш Совет илендә, Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә, гаять зур иҗади эш башланды.

1920 нче елның 27 нче маенда РСФСР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы, Россия Совет Социалистик Федератив Республикасының бер өлеше булган Татарстан республикасын төзү турында Ленин имзасы белән декрет иглан итте. В. И. Ленин һәм И. В. Сталин—Татарстан АССР ны төзүнең иҗадчылары һәм инициаторлары. Лениннең бөек көрәштәше Иосиф Виссарионович Сталин Татарстан республикасын төзү турындагы материалларын эшләүдә үзе җитәкчелек итте һәм бу мәсьәлә буенча РСФСР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Совнаркомы утырышында доклад ясады.

1920 нче елның 25 нче июнендә, Казанда, тантаналы утырышта, элекке Казан губернасының башкарма комитеты властьны Татарстан АССР революцион комитеты кулына тапшырды.

Кыска тарихи 20 ел эчендә иркле татар халкы, коммунистлар партиясе һәм хезмәт ияләренең юлбашчысы иптәш Сталин җитәкчелегендә, бөтен Советлар Союзы белән бергә, социалистик төзелешнең данлыклы җиңү юлын үтте. Ярым кустарь промышленносте, артта калган авыл хуҗалыгы белән элекке хәерче Казан губернасы, пролетариат диктатурасы шартларында, бөек рус халкының ярдәме белән, алдынгы индустриаль-аграр республикаларның берсе булып әверелде.

Элекке Казан губернасында эре промышленность юк иде. Хәзер бездә мех, күн аяк киемнәре, киез итек, машина төзелеше, урман эшкәртү промышленносте, ясалма каучук производствосы һәм энергетика бик нык үсте. Промышленность нефте чыгаруга хәзерлек, җирле таш күмер һәм башка төрле казылма байлыклар эзләү эше алып барыла. Куйбышев гидроузелы төзелешен тәгәлләү республикада җитештерү көчләренең тагын да үсүе өчен иксез-чиксез өстәмә байлыклар бирәчәк.

Авыл хуҗалыгында гаять зур уңышлар бар. Татарстанда крестьян хуҗалыкларының 94,5 проценты колхозларга берләште, алар барлык чәчү мәйданнарының 99,6 процентын эшлиләр. Иң яңа машина һәм агрономия техникасыннан файдаланып, алдынгы колхозлар югары, йөзпотлы уңышка ирешәләр. Совет авылының тормышы елдан-ел яхшы һәм культуралы булып әверелә бара.

Татар халкының формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культурасы чәчәк ата. Меңнәрчә башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләрнең, уннарча техникумнарның һәм ВУЗ ларның ишекләре барлык хезмәт ияләре өчен киң ачылганнар. Театрлар, культура йортлары, клублар, кетепханәләр, музейләр, больницалар, санаторийләр, курортлар халыкка киң хезмәт күрсәтәләр. Татарстан бюджеты буенча 1939 нчы елда социаль-культура чараларын үстерүгә 203,4 миллион сум—бөтен бюджетның 51,5 проценты җибәрелде.

Бөтен Советлар Союзы халкы шикелле үк, Татарстан халкы да үз Ватанын ялкынлы рәвештә сөя. Республикабызның хезмәт ияләре Верховный Советларга һәм җирле Советларга булып үткән сайлауларда үзләренең мораль-политик бердәмлекләрен һәм Ленин—Сталин партиясе тирәсенә тупланган булуларын күрсәттеләр.

Татарстан АССР ның егерме еллыгы көне орденлы Татарстанның тарихына бөек тантана көне булып керәчәк. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары алдында, партия, комсомол, җәмагат оешмалары алдында зур политик бурыч тора. Бу бурыч—республикабызның XX еллыгын коммунистик җәмгыять төзелешенең барлык фронтларында гаять зур яңа җиңүләр белән билгеләп үтү өчен, республикабыздагы барлык хезмәт ияләренең игтибарын бу бөек бәйрәмгә хәзерлек эшенә туплау.

Фабрикаларда һәм заводларда, колхозларда, совхозларда һәм МТС ларда, барлык учреждениеләрдә Татарстан АССР ның XX еллыгы хөрмәтенә промышленность һәм финанс планнарын срогыннан элек үтәү, язгы чәчүгә иң тиз арада хәзерләнү һәм аны югары сыйфатлы итеп үткәрү өчен, җәмагат терлекчелеген үстерү, 1940 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә хәзерләнү өчен социалистик ярыш җәелә. Бу ярышны көннән-көн киңәйтергә кирәк.

Шәһәр төзеклеге, культура төзелеше, сәламәтлек саклау, илнең оборона сәләтен ныгыту мәсьәләләре дә юбилейгә хәзерлекнең үзәгендә торалар. Аларны хәл итүгә халыкның киң массасын тартырга кирәк. Зур Фергана каналы төзелеше—Советлар Союзы халыкларының хезмәт энтузиазмының ачык күрсәткече. Столбище районының „13 лет Октября" артеле колхозчыларының гүзәл башлап җибәрүләре башка барлык колхозлар тарафыннан алкышлап каршыланырга тиеш. Татарстан АССР ның XX еллыгына культуралы юллар төзүгә, шәһәрләрнең, авылларның төзеклеге эшенә Татарстанның барлык хезмәт ияләрен тупларга кирәк.

Татарстан АССР ның данлыклы юбилеен без укый-яза белмәүне тулысынча бетерү белән каршы алырга тиешбез. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары, комсомол, халык мәгарифе органнары колхозчылар арасында, колхозчы хатын-кызлар, предприятиеләрдәге эшчеләр һәм халыкның башка группалары арасында зур эш үткәрергә тиешләр. Гаять әһәмиятле бу чараның уңышлы үтүен тәэмин итәргә кирәк.

Осоавиахим һәм физкультура оешмалары СССР ның, гүзәл Ватанабызның чикләрен саклауга басарга һәр минут хәзер торучыларны—ГТО, Ворошиловча атучы, һава һәм химия һөҗүменә каршы оборона значкистларын хәзерләүне киң җәелдерергә тиешләр.

Партия һәм Совет хөкүмәте татар халкының талантларын чәчәк аттыру өчен барлык шартларны тудырдылар. Бу еллар эчендә партия, совет, хуҗалык оешмаларының сәләтле җитәкчеләре, инженерлар, техниклар, профессорлар, врачлар, композиторлар, язучылар, художниклар, скульпторлар, артистлар үстеләр. Авылларда, предприятиеләрдә, уку йортларында художестволы үзешчәнлек киң үсә. Республикабызның тантаналы XX еллык бәйрәме көнендә сәнгать работниклары һәм художество үзешчәнлек түгәрәкләре халыкка үзләренең иҗадларын, уңышларын күрсәтергә тиешләр. Бу өлкәдә Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Идарәсе, Мәгариф Халык Комиссариаты һәм комсомол, шәһәр һәм авылның культура учреждениеләре алдында зур эш тора.

Юбилейгә хәзерлек көннәрендә халык арасында агитация-масса эшен тагын да киңрәк җәелдерергә, аңа меңнәрчә яңа агитаторлар һәм пропагандистлар тартырга кирәк. Күргәзмәләр—республиканың, шәһәрләрнең, поселкыларның, авылларның үткән тарихи вакытларын җанлы рәвештә күрсәтү, социалистик төзелешнең гаять зур уңышларын күрсәтү, атаклы кешеләрне, стахановчыларны күрсәтү, аларның эш тәҗрибәләрен башкаларга күчерү—массовый агитациянең иң эшлекле төрләреннән берсе.

Агитация-масса эшләрен җәелдерүдә партия, комсомол һәм профсоюз оешмалары өстенә гаять зур җаваплылык төшә. Ләкин республиканың юбилеенә хәзерлекнең бөтен политик әһәмияте әле һәммә җирдә дә аңлап җиткерелмәгән. Районнарда төзелгән комиссияләр я бөтенләй эшләмиләр, яисә кабинетта планнар төзү белән чикләнәләр. Мәсәлән, Питрәч районы җитәкчеләре бары тик юбилей комиссиясенең утырышы белән генә чикләнгәннәр. Биредә XX еллыкка хәзерлекнең планын төзергә дә вакыт таба алмаганнар. Татарстан АССР нын XX еллыгына һичбер төрле җидди хәзерлек алып бармаучы Зеленодольский оешмаларының җитәкчеләре турында да шул ук сүзне әйтергә мөмкин. Биектауда юбилейгә хәзерлекнең яхшы гына планы төзелгән. Анда социалистик ярыш турында, укый-яза белмәүчелекне бетерү, күргәзмәләр, оборона-физкультура эше турында әйтелә. Ә эштә нәрсә күрәбез? Меңнән артык укый-яза белмәүче кешеләр укудан читтә калдырылганнар. Оборона-физкультура эшенә һичбер әһәмият бирелми. Кешеләр бөтен эшне кабинет язмаларына кайтарып калдырырга уйлыйлар.

Татарстанның барлык оешмалары, бөтен җәмагатчелеге, Татарстанның XX еллыгына хәзерлек эшенә актив рәвештә катнашырга тиешләр. Бу мәсьәләне партия, комсомол, профсоюз, колхоз җыелышларында тикшерергә кирәк. Барлык авыл советларында, эре предприятиеләрдә, совхозларда, МТС ларда, колхозларда юбилей комиссияләре төзергә һәм аларның эшләренә хезмәт ияләренең киң массасын тартырга кирәк. Тантаналы көнне—25 нче июнне лаеклы рәвештә каршы алуга барлык хезмәт ияләрен туплау өчен, юбилейгә хәзерлек планнарын эшчеләрнең, колхозчыларның, хезмәткәрләрнең җыелышларында тикшерергә кирәк. Татарстан АССР ның XX еллыгы исемендәге социалистик ярышта актив катнашу—һәрбер хезмәт иясенең намуслы эше.

ТАССР ның XX еллыгына хәзерлек

ТАТАРСТАН ТУРЫНДА КИНО-ФИЛЬМ

Татарстан республикасының XX еллык юбилеенә Союзкинохроникаңың Москва студиясе, Татарстан студиясе белән берлектә, Татарстан турында тавышлы махсус кино-фильм хәзерли. Хәзер фильмнең сценарием төзү өстендә эш алып барыла. Ике бүлектән торган бу фильмдә орденлы Татарстан республикасының промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура өлкәсендәге үсешен күрсәткән аерым кадрлар алыначак. Шулай ук кино-фильмдә Татарстанның алдынгы кешеләре дә күрсәтеләчәк.

ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

Татарстанның Крайны Өйрәнү Үзәк Музее республикабызның XX еллык юбилеенә зур күргәзмә хәзерли. Күргәзмәнең тематик планы төзелде һәм расланды инде. Анда элеккеге Казан губерниясенең тарихы, Совет власте шартларында Татарстан республикасының үсеше диаграммаларда, фотодокументларда күрсәтеләчәк.

Хәзер музейнен фәнни работниклары музейдә булган тарихи материалларны туплау һәм тәртипкә китерү өстендә эшлиләр. Татарстанның художниклары юбилей күргәзмәсе өчен күп кенә рәсемнәр хәзерлиләр.

Музейнең „Безнең республикабыз" дигән бүлегенә яңа материаллар өстәлә.

БАЛАЛАРНЫҢ ҮЗЕШЧӘНЛЕК СӘНГАТЕ КӨЧЛӘРЕНӘ СМОТР

ВЛКСМ ның Татарстан өлкә һәм шәһәр комитетлары, Татарстан республикасының XX еллыгына багышлап, укучы балаларның үзешчәнлек сәнгате көчләренә смотр үткәрергә карар бирделәр.

Смотр башта мәктәпләрдә, аннан соң районнар һәм шәһәр күләмендә үткәреләчәк. Данлыклы юбилей көннәрендә республика күләмендәге смотр булачак.

Хәзер мәктәпләрдә һәм балалар учреждениеләрендә смотрга хәзерлек эшләре башланды. 29 нчы январьда комсомолның шәһәр комитетында үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре җитәкчеләренең киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмәдә сәнгат мастерларыннан Татарстанның халык артисты Любин, Татарстанның халык артисткасы Измайлова, атказанган артисткалар—Ахметова һәм Кадмина иптәшләр (барлыгы 30 га якын кеше) катнашты. Смотрга хәзерлек эшендә үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре җитәкчеләренә консультацияләр бирү өчен композитор Ключарев, артистлардан Любин, Измайлова, Ахметова, Кадмина иптәшләр сәнгатнең аерым тармаклары буенча эш алып барачаклар.

Шулай ук балаларның авиамоделизм, планеризм, туризм эшләренә дә смотр булачак.

1940 НЧЫ ЕЛДА КОММУНАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ

Яңа коммуналь предприятиеләр төзү, шәһәрне һәм район үзәкләрен төзекләндерү, яңа торак йортлар төзү һәм искеләренә ремонт ясау өчен 1940 нчы елны Татарстанда 25 миллионга якын акча тотылачак.

Волга водопроводы төзелешен (Казан) тәмамлау өчен 1 миллион 500 мең сум акча җибәрелде. Трамвай юлларын Свердлов урамыннан Островский урамына күчерү өчен 400 мең сум һәм укытучылар өчен салына торган 28 квартиралы йортны төзеп бетерү өчен 100 мең сум акча бирелә.

Быел Казанда 24 квартиралы яңа торак йорты төзү башланачак. Бу йорт Бауман урамына, хәзерге вакытта дәүләт звериннецы урнашкан урынга салыначак.

Районнардагы коммуналь төзелеш эшләре өчен дә шактый күләмдә акча җибәрелә. Алабугадагы 200 киловатт куәтле электростанцияне төзү тәмамланачак. Бөгелмәдә яңа мунча төзергә һәм водопровод төзүне дәвам иттерергә карар бирелде. Болардан тыш, шәһәрләрне һәм район үзәкләрен—урамнарны, күперләрне ремонтлау, бакчалар, скверлар һ. б. төзү өчен 4 миллион 675 мең сум акча җибәрелә. Торак фондына капиталь ремонт ясауга 10 миллион сумнан артык акча тотыла. (ТатТАСС).

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 30 январь. (ТАСС). Кичә кич белән чыгарылган белдерүдә „авиациянең һәм артиллериянең бер кадәр активлыгы" турында күрсәтелә.

Бүген иртә белән чыгарылган белдерүдә „яңа бер нәрсәнең дә булмавы" әйтелә.

БРЮССЕЛЬ, 30 январь. (ТАСС). „Журналь" газетасының хәрби күзәтүчесе, һаваларның яңгырлы булуы фронттагы һәр төрле активлыкны иң кечкенә күләмгә кадәр киметте, дип күрсәтә. Франция солдатлары яңгырлар аркасында үтә алмаслык дәрәҗәдә диярлек булып калган юлларны тазарту белән шөгыльләнәләр.

Газета үзенең күзәтүен Франциянең көнчыгыш һәм төньяк районнарыннан халыкны күчерү турындагы хәбәрләрне юкка чыгару белән тәмам итә. Шуның белән бергә газета, властьларның инде халыкны күчерү буенча чаралар хәзерләгәнлекләрен таный.

БЕРЛИН, 30 январь. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәгечә хәбәр итә: „Безнең самолетлар, Төньяк диңгез өстендә разведка очышлары үткәргән хәлдә, кичә дошманның коралланган сәүдә пароходларының конвой астындагы кәрванына һәм сакчылык карабларына һөҗүм иттеләр. Дошманның көчле рәвештә булган зенит утына һәм Англия истребительләре тарафыннан ачылган утка карамастан, безнең авиация дошманның коралланган 7 сәүдә пароходын һәм 2 сакчылык карабын юкка чыгаруга иреште. Гартльпуль тирәсендә дошманның 1 истребителе бәреп төшерелде. Безнең самолетлар үз базаларына кайтып керделәр".

БЕРЛИН, 30 январь. (ТАСС). Дания газеталарының Лондон хәбәрчеләре, — Англия ярларына Германия авиациясенең соңгы һөҗүме — сугыш башланганнан бирле иң зур һөҗүм, дип язалар. Англиянең көнчыгыш ярындагы барлык шәһәрләрдә, Шотландиягә кадәр 600 километрлык җирдә, һава тревогасы игълан ителгән. Бу һөҗүм Англиягә көчле рәвештә тәэсир иткән, чөнки ул метеорология шартлары начар булган вакытта үткәрелгән.

АНГЛИЯ—ЯПОНИЯ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

ТОКИО, 30 январь. (ТАСС). Япония матбугаты „Асама—Мару" пароходы белән булган инцидентка игътибар юнәлдерүне дәвам итәрә. Газеталар, хөкүмәтнең Англиягә каршы кискенрәк чаралар күрүен таләп итәләр һәм „Англиянең хәрәкәтләре Япониянең игътибарын киметә" дип күрсәтәләр.

„Ници-Ници" газетасы,—Япония протестына Англиянең җавабы канәгатьләнерлек түгел, ди.

„Кокумин" газетасы болай яза: „Япониянең протестында 21 герман пассажирын Япониягә кайтару турындагы таләп булуга карамастан, Англиянең җавабы бу мәсьәләгә һич тә кагылмый. Англия хөкүмәтенең шундый позициясе Англиянең Япониягә дошманлык күрсәтүе булып тора".

Матбугат работникларының 29 нчы январьда булган конференциясендә Япониянең чит ил эшләре министрлеге вәкиле, министрлекнең Англиягә икенче протестны хәзерләве турында белдерде.

ЧЕРЧИЛЛЬ РЕЧЕ

ЛОНДОН, 30 январь. (ТАСС). Диңгез эшләре министре Черчилль шушы көннәрдә Манчестерда речь белән чыкты. Ул,—гәрчә сугышның күпме вакыт дәвам итүен берәү дә белмәсә дә, сугышны туктату турында сүз булуы да мөмкин түгел, дип аеруча күрсәтеп үтте. Сугышны дәвам иттерү өчен илнең бөтен байлыкларын туплау кирәклеген күрсәтеп, Черчилль, аерым алганда, сугыш промышленностына 1 миллион хатын-кызны тартырга чакырды.

Черчилльнең хатын-кызлар турында белдерүе тред-юнионнар даирәләрендә зур ризасызлык тудырды. Машина төзелеше эшчеләре союзының генеральный секретаре Черчилльнең чакыруын „кыргый чакыру" дип атады һәм әле йөзләрчә меңләп эшсезләр барлыкны искә төшерде. Машина төзелеше һәм судноляр төзелеше эшчеләре федерациясенең секретаре Джилберт,—бер миллионнан артык эшсез бар вакытта промышленностька бер миллион хатын-кызны тартуга мохтаҗлык юк, дип белдерде.

Шуны күрсәтеп үтәргә кирәк, хәттә „Дейли мейл" газетасы да Черчилльгә беренче чиратта бер миллион эшсезгә эш бирергә кирәклекне күрсәтә.

АКШ һәм Япония

НЬЮ-ЙОРК, 30 январь. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, игътибарлы даирәләрдәге мәгълүматлар буенча, АКШ ның дәүләт секретаре Хэлл конгресс лидерларына, дәүләт департаментының хәзер Япониягә товарлар чыгаруны тыю ягында тормавы турында информация ясаган.

БОЛЬШЕВИСТИК ОЕШКАНЛЫКНЫҢ ҖИҢҮЕ

М. В. СТРЕКАЛОВСКИЙ

Төньяк Диңгез юллары Баш идарәсе начальнигының урынбасары

Хәрәкәттәге бозваткычта Советлар Союзының кызыл байрагын төньякның тикшерелмәгән киңлекләре аркылы үткәргән батыр улларын бөек Совет халкы кайнар рәвештә кочаклый.

„Седов"ның героик хәрәкәтендәге иң гүзәл нәрсә бу хәрәкәтнең алдан җентекләп хәзерлек булмаса да бик яхшы итеп үткәрелүендә. Эшнең уңышын хезмәтне, укуны, көнкүрешне дөрес оештыру хәл итте. Уңышны яхшы итеп куелган партия-масса эше тәэмин итте. Бу эш бөтен коллективны берләштерде, аны Арктика стихиясенә каршы көрәштә туплады.

Седовчыларның җиңүе очраклы түгел. Ул—большевистик оешканлыкның ачык дәлиле.

Седовчылар үзләренең героик эшләрен бөтен Совет халкының мәхәббәте һәм ярдәме шартларында, партиянең, хөкүмәтнең һәм иптәш Сталинның үзенең игътибары һәм кайгыртучанлык күрсәтүе шартларында алып бардылар.

Карабның хәрәкәтен игътибар белән күзәтеп, иптәш Сталин Төньяк Диңгез юллары Баш идарәсенең җитәкчеләрен „Седов" ны бозлар арасыннан чыгаруга вактында хәзерләнергә кирәклек турында кисәтте.

Иптәш Сталинның искә төшерүе Гренландия диңгезенә булган экспедицияне ныклап хәзерләүне тәэмин итте. Бозларның чикләре һәм боз шартларын белү өчен бу диңгез районына җәнлекләр аулый торган „Мурманец" карабы җибәрелгән иде. Бу карабның командасы тарафыннан алып барылган күзәтүләр хөкүмәт карары буенча „Седов"ка ярдәмгә җибәрелгән „И. Сталин" бозваткычының экипажы өчен соңыннан гаять кыйммәтле материал булдылар.

Асылда экспедицияне хәзерләү җәй көне үк, „Седов" Франц-Иосиф җиреннән төньякка таба хәрәкәт иткән вакытта ук башланган иде. Төньяк Диңгез юллары Баш Идарәсе начальнигы—Советлар Союзы герое иптәш Папанин бу вакытта „И. Сталин" бозваткычында иде һәм ул бу карабның командасы алдына кышкы кыен рейска алдан ук хәзерләнү бурычын куйды.

Котып навигациясе тәмам булганда „И. Сталин" бозваткычы Гренландия диңгезенә походка тулысынча хәзер иде инде. Карабның механизмнары җентекләп тикшерелде һәм тәртипкә кертелде. Нак хөкүмәт билгеләгән срокта—15 нче декабрьдә бозваткыч Мурманскидан „Седов"ка таба юнәлде.

Карабның личный составы тәҗрибәле моряклардан—Арктика походларында күп тапкырлар катнашкан котыпчылардан тупланды. Карабның бортына тулы күмер һәм су запасы, 9 айга җитәрлек азык запасы, Котып кирәк-яраклары һәм Арктикада төнлә очу өчен яраклаштырылган ике самолет алынды. Бозваткычның экипажы герой седовчыларга илебездән күп санлы бүләкләр—свежий кыярлар, помидорлар, лимоннар, мандариннар, свежий ит, тере кошлар, газета һәм журнал комплектлары, хатлар һәм күп кенә башка нәрсәләр алып бардылар.

Без көткәнчә, Баренц диңгезе бозваткычны рәхимсез шторм белән каршы алды.

Начар һава 6 тәүлек чамасы дәвам итте. Карабка гаять зур дулкыннар килеп бәрелде. Аның янтаюы 45 градуска җитте. Дулкын күп урынлы коткару катерын алып китте, азык һәм ягулык тутырылган берничә мичкәне ватты. Бу капитан мостигына кадәр күтәрелде, штурман рубкасындагы пиалаларга бәрелде. Эчәр өчен алынган 500 тонна чамасы суны түгәргә туры килде, чөнки карабның хәрәкәтен көчәйтергә кирәк иде. Карабны йөртүчеләрнең эше гаять кыен булды. Караб һичбер төрле ориентирлар булмаган районнардан барды. Котып төненең караңгылыгы һәм давыл карабның координатларын билгеләргә дә мөмкинлек бирмәде. Бу авыр сынауны флагман карабы намус белән үтәде һәм бик яхшы йөзү һәм ныклык сыйфатлары күрсәтте.

Юлны кыскарту өчен караб бер кадәр гадәттә булмаган юлдан—Скандинавия ярым атавының төньяк ярлары буеннан барды. Бозваткыч Медвежий атавын үтте, диңгездә йөрүчеләр арасында суының сайлыгы белән атаклы булган Шпицберген банкаларын үтте.

Гренландия диңгезе бозваткычны түбән температура белән каршы алды. Шторм дәвам итте, карабка калын боз катты. Командa кулларына балталар һәм көрәкләр тотып бозны чапты һәм карабны күп тонна авырлыгындагы боздан коткарды.

Дулкыннардан котылу теләге белән, капитан Белоусов „Седов"ка таба барганда карабны Шпицбергеннең көнбатыш яры буйлап алып барды. 23 нче декабрьдә караб бозлар арасына килеп керде. Озак та үтмәде, караб 9 баллы бозлар арасына килеп керде. Караб куәтле боз кырлары аркылы „Седов"ка таба үтәргә тырышты. Моннан соңгы хәрәкәт зур куркыныч белән барды: күмер запасы бетеп килә иде. Шунлыктан иптәш Папанин ягулык запасы һәм су алу теләге белән Баренцбургка барырга карар бирде.

Ләкин күмер төяүне өзәргә туры килде: „Седов"ның хәле кыенлашты. Аның тирәсендәге боз хәрәкәткә килде һәм карабны кыса башлады.

„И. Сталин" бозваткычының бозларга каршы яңа сугышы тагын да рәхимсезрәк булды. Ул бозлар аркылы үтеп һәм алар арасында кыен маневрлар ясап, „Седов"ка таба бару юлын дәвам иттерде.

13 нче январьда „И. Сталин" бозваткычы „Седов"ның уң як бортына килеп туктады. „Седов" ның 812 көн дәвам иткән хәрәкәте тәмам булды.

Батырларны боз пленлегеннән коткару өчен Ватаныбыз тарафыннан Арктиканың югары киңлекләренә җибәрелгән Совет кешеләре белән седовчылар гаять зур шатлык хисе белән очраштылар.

Седовчылар барлык кыенлыкларны җиңеп Ватаныбызга кайталар, алар җиңүчеләр булып кайталар. Алар фән өчен, куәтле социалистик Ватаныбыз өчен бөек батырлык эшләделәр.

Аларга, чорыбызның Колумбларына дан! Халыкка дан! Шушындый батыр кешеләрне тәрбияләгән Сталинга дан! (ТАСС).

РӘСЕМДӘ—сулдан: „И. Сталин" бозваткычы Гренландия диңгезендә. Унда: „И. Сталин" бозваткычының бозланган якорь чылбырларын куптару. (Рәсемнәр Баренцбургдан Мурманскига „Үзбәкстан" пароходында китерелгәннәр). Д. Дебабов фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

СЕДОВЧЫЛАРЫБЫЗГА ХӨРМӘТ ҺӘМ ДАН!

Ниһаять алар, бу батыр геройлар, данлыклы седовчыларыбыз безнең янда! Без алар турында никадәр уйладык, без аларның боз белән чолгап алынган карабларында алар белән берлектә үзебезнең фикерләребез белән армый-талмый никадәр озын көннәр һәм айлар үткәрдек.

Үзенең бөек Ватанына чын күңелдән бирелгәнлек һәм мәхәббәт белән нык тупланган 183 миллионлы куәтле халкыбызның һәр вакыт яңа геройларны һәм героик батырлыкларны тудырачагына ышанам. Илебез бу геройлар белән бик урынлы рәвештә горурлана ала.

Седовчыларыбызга хөрмәт һәм дан!

СССР ның халык артисты И. М. МОСКВИН.

ФӘН ГЕРОЙЛАРЫ

Папанинның, Федоровның, Ширшовның һәм Кренкельнең героик экспедициясеннән соң булган „Седов" бозваткычының ике елдан да артыграк сузылган хәрәкәтенең фән өчен гаять зур әһәмияте хәзер үк инде ачык. Ләкин бу хәрәкәт вактында седовчылар тарафыннан ясалган метеорология, геофизика, гидрология һәм биология күзәтүләренең бөтен көндәлекләре басылып чыкканнан соң гына аңа җитәрлек дәрәҗәдә тулы бәя биреләчәк. Бу экспедицияләр икесе дә һавада да, суда да, хәттә җирнең мәңгелек боз шартларындагы котыпларында да органик тормышның тукталмавын күрсәттеләр. Седовчылар төрле фәнни күзәтүләр челтәрен җир шарының әлгәре уйга да килүе мөмкин булмаган пунктлары белән тулыландырдылар.

Батырларча эшләнгән бу эшкә ирексездән сокланасың!

Н. А. Морозов.

СССР фәннәр Академиясенең почетлы члены.

Советлар Союзы геройлары Батыршин һәм Чернопятко иптәшләр Казанда

Хасан күле буендагы сугышларда күрсәткән геройлыклары өчен Советлар Союзы герое дигән исемне алган ике дус—Гыйлфан Батыршин һәм Иван Чернопятко иптәшләр, үзләренең кышкы каникуллары вактында, Гыйлфанның туганнары янына Казанга кунакка кайттылар.

Алар икесе дә Хәрби академиядә укып, кышкы зачет сессиясендә имтиханнарын отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырганнар.

Батыршин һәм Чернопятко иптәшләр Казанда булган вакытларында Кызыл Армиянең командирлары, политработниклары һәм сугышчылары белән, Ленин районының допризывниклары белән, шулай ук укучы балалар һәм мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар белән очраштылар. Бу очрашуларда алар Хасан күле буенда булган вакыйгалардан эпизодлар сөйләделәр.

Союзкинохрониканың Татарстан студиясе аларны киножурналга төшерде.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

30 нчы январьда фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның резервларына һәм хәрби объектларына күп кенә уңышлы атакалар ясады.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Комсодлар һәм фабзавместкомнар председательләренең

шушы ел, 2 нче февральдә Чернышевский урмындагы 2 нче йортның 59 нчы квартирасында үткәрелергә билгеләнгән

РАЙОН КИҢӘШМӘСЕ

15 нче Үзәк саклык кассасы бинасында (Бауман урамы, 38) үткәрелә.

РАЙКОМСОД.

172—1

БҮГЕН ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

— Татар Дәүләт Академия театры—бүген һәм иртәгә премьера Булак арты „республикасы"; талоннар: бүген 106, иртәгә 107.

Зур Драма театры—Бакчалар чәчәк ата; талон 89; иртәгә Маскарад; талон 90.

Дәүләт Циркы—бүген һәм һәр көн зур программада цирк уены.

„Электро"—Инженер Кочинның ялгышуы, „Унион"—Минин һәм Пожарский. „Кызыл Йолдыз"—Дуслар, „Чаткы"—Дуслар, „Пионер"—көндез Федька, кич Тракторчылар көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс, „Колхозник"—Бөек бүләк, „Рот-Фронт"—Бөек гражданин (1 нче сериясе) Культура сарае—Инженер Кочинның ялгышуы.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АЛДЫНГЫЛАРЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘГЕ КИҢӘШМӘСЕ ЯБЫЛДЫ

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсенең 30 нчы январьдагы кичке утырышында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссары иптәш Черзор председательлек итә. Ул беренче сүзне Столбище районы, „Память Ленина" колхозының хата-лаборатория мөдире иптәш Полянкинга бирә.

Иптәш Полянкин бу колхозның гаять зур казанышлары турында зур речь сөйли. Колхоз үткән елны игенчелектән, яшелчәлектән, терлекчелектән бик зур доход алды. Колхоз эшенә чын күңелдән бирелеп эшләү нәтиҗәсендә, колхозчыларның хезмәт көннәренә тигән уңыш гаять зур. Бу колхоз һәрбер хезмәт көненә яшелчә буенча гына да 24,5 килограмм уңыш бүлде.

Актаныш районы, „Красный пахарь" колхозының дуңгыз асраучылык фермасы мөдире иптәш Евдокимов социалистик терлекчелекнең бик тизлек белән алга китүе турында ачык мисалләр китерә. Бу колхозның дуңгыз асраучылык фермасы үткән елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты. Колхоз беренче дәрәҗәле диплом, җиңел автомашина һәм 10 мең сум акча белән бүләкләнде. Иптәш Евдокимов 1940 нчы елны һәрбер ана дуңгыздан 22 дуңгыз баласы алып үстерергә, сарык асраучылык фермасы оештырырга сүз бирә.

Биектау МТС ы тракторчысы иптәш Спиридонова социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенең киң җәелүе турында сөйли. Ул 1940 нчы елны һәрбер универсаль тракторы белән 500 гектар эшләргә йөкләмә ала. (Норма 250 гектар).

Яңа Чишмә районы, „Красный Октябрь" колхозының ат караучысы иптәш Шерстобитов ат асраучылык эшенә аеруча әһәмият бирергә кирәк икәнлеге турында әйтеп үтә.

— Мин, 8 елдан бирле колхоз атларын тәрбиялим. Атның колхозда тоткан роле бик зур. Шулай ук безнең данлыклы Кызыл Армиябез өчен дә яхшы, җитез атлар кирәк. Безнең колхоз бу тармакта үзенең бурычын намус белән үти, ди.

Авыл хуҗалыгы Ветеринария институты профессоры иптәш Сырнев фән работникларының бурычларына тукталып үтә. Фәнне производство белән нык бәйләп алып барганда гына фән көтелгән нәтиҗәне бирә ала, ди.

Кичке утырышта тагын байтак иптәшләр речь белән чыктылар. Алар 1940 нчы елны югары иген уңышы алу өчен колхоз производствосында чикләнмәгән мөмкинлекләр барлыгын күрсәттеләр.

***

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәнең 31 нче январьдагы иртәнге утырышында фикер алышулар дәвам итте. Фикер алышуларда түбәндәге иптәшләр катнашты: Андреев (Чистай районы, „Победа" колхозының дуңгыз асраучылык фермасы мөдире), Беляков („Яңа Тормыш" колхозы), Косушкин (Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссары урынбасары), Галләмова (Тымытык районы зоотехнигы), Князева (Куйбышев районы, „Возраждение" колхозы звеноводы), Җәмалиева (Буа районы, Каганович исемендәге колхоз председателе), Әүхәдиев (Арча районы, „Кызыл Почмак" колхозы хисапчысы).

Фикер алышулар тәмам булганнан соң, ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев үзенең докладына буенча йомгаклау рече белән чыкты.

1940 нчы елны авыл хуҗалыгы эшләре буенча Татарстан, Чувашстан һәм Мордовия республикалары арасында социалистик ярыш договорына кул куелды.

Аннары, 1939 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашучы колхозларга бүләкләр тапшыру булды.

Киңәшмә гаять зур күтәренкелек белән иптәш Сталинга хат һәм Татарстанның барлык колхозчыларына, совхоз һәм МТС эшчеләренә, агрономнарга, зоотехникларга, социалистик игенчелекнең фән работникларына мөрәҗәгат кабул итте.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе шуның белән үзенең эшен тәмам итте.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 704 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 425.